Фирдүс ДӘҮБАШ

# БӘХЕТ КИТЕРҮЧЕ ИСЕМНӘР

Фирдүс ДӘҮБАШ

# БӘХЕТ КИТЕРҮЧЕ ИСЕМНӘР

Казан — 2016

Ихлас

УДК 80/81
ББК 81.2Тат
Д94

*Охраняется Законом РФ “Об авторском праве и смежных правах”. Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения автора.*

Филология фәннәре докторы
**Марсель Әхмәтҗанов** редакциясендә

**Фирдүс Дәүбаш**

Д94 Бәхет китерүче исемнәр. Төрки-татар исемнәре аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Ихлас, 2016. – 64 б.

**ISBN 978-5-906701-84-8**

Балага исем кушу – җаваплы эш. Кешенең исеме – аның гомерлек юлдашы. Исем кешенең тормышына тәэсир итә. Бала бәхетле булуын теләсәгез, аңа теләсә нинди мәгънәсез, бармактан суырып чыгарылган исем бирмәгез, ата-бабаларыбыздан килгән бай рухи мирасыбызга таянып эш итегез.

Бу китапта рухи хәзинәбезнең үрнәкләре – бәхет китерүче саф татар исемнәре тупланган.

**ISBN 978-5-906701-84-8**

© Фирдүс Дәүбаш, 2016
© «Ихлас», макет, 2016

# ИСЕМ КУШУ

## *Бәхет китерүче исемнәр*

Балага матур исем куегыз. Яңа туган кешенең исеме аның гомере буенча яңгыраячак, гомерлек юлдашы булачак. Исем кешене шәхес буларак аерып тора, аның милләт күрсәткече санала. Балага бирелгән исем ата-ананың зәвекъ һәм җаваплылыгын, белем вә мәдәни дәрәҗәсен чагылдыра. Куелачак исемнең мәгънәсенә игътибар итегез, исем буларак кулланылачак сүз үз телебезнең сүзе булсын, газиз ана телебез гаять бай. Дөньядагы һәр халыкның үзенә генә хас исемнәр байлыгы бар. Сез дә балагызга Алсу яисә Айдар кебек матур татар исемен бирегез. Исемнәр тудыру – халык иҗатының бер төредер һәм ул бер яктан халкыбызның иҗади осталыгын күрсәтсә, икенче яктан туган телебезнең ямен, сүз байлыгын исбатлый.

Балаларга төрле чорларда бирелгән исемнәр буенча илебезнең тарихын өйрәнергә була. Октябрь революциясенә кадәр иҗтимагый тормышта ислам диненең роле зур булган, ул чорда гарәп-фарсыдан килгән дини исемнәр еш кулланылган. Ул исемнәр татарлар арасында XVIII гасырда Екатерина II нең (“Әби патша”ның) билгеле указларыннан соң киң итеп тарала башлый. Тел галиме Гомәр Саттар-Мулилле гарәп һәм фарсы исемнәренең XVII йөз азакларына чаклы безнең халыкта артык киң таралышка, кулланылышка һәм популярлыкка ия булмауларын күрсәтә. “Бу чорга кадәр татарларда борынгы болгар-татар кабер ташларындагы, сан алу кенәгәләрендәге һәм башка тарихи язма чыганаклардагы кеше исемнәре нәкъ менә шуны раслыйлар”, – дип яза ул галим. Бу факт татарлар ислам динен 922 нче елда кабул иткәннәр дип белдерүнең дөреслеккә туры килмәвен исбатлаучы җитди бер дәлил дә. Ул чорның Идел-

Кама Болгарстаны җитәкчесе Алмыш хан һәм аның якыннары көньяктан килгән динне кабул иткәннәрдер, әмма гади халыкка ислам динен чын-чынлап, киң рәвештә Екатерина II керткән. Бу процессның, ягъни Идел буе һәм Уралда ислам дине таралуының катлаулы тарихы һәм укучыларыбызга әлегә кадәр билгесез булып калган кызыклы яклары бар...

XVIII гасырга тикле татар исемнәре хәзинәсен саф түрк (төрки-татар) теленең сүзләре тәшкил иткән, ләкин ислам дине килгәч тә, чын татар исемнәре бөтенләй юкка чыкмаган, алар этнолингвистик катлам буларак сакланган.

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исемен инкарь итәрме, –*

дип классик шагыйребез Дәрдмәнд юкка гына язмаган димәк. Социализм елларында, билгеле бер күләмдә вөҗдан иреге яулангач, милләтебез үз теленең сүзләрен кеше исемнәре буларак яңадан киң рәвештә кулланышка кертә. Ислами исемнәр кушу очраклары ул чорда сирәк була. Әмма ул елларда исем иҗаты идеологик юнәлештә бара, революция лексикасы кеше исемнәренә әверелә.

Татар баласына исем кушуда өр-яңа чор 1990 нчы елда Татарстан Республикасы төзелеп, татар теленә дәүләт теле статусы бирелгәч башлана. Ниһаять  халкыбыз үз асылын кайтару эшенә керешә. Демократик үзгәрешләр, татар халкының милли үзаңы уяну балаларга исем кушуда да чагылыш таба. Рухи үсеш милли телдә барган бу чорда, әлбәттә саф татар исемнәренә өстенлек бирелә. Халкыбызның андый исемнәр иясе булган уллары-кызларының  бу елларда олы мәртәбәләргә ирешүе, телебез хәзинәсенең  җәүһәрләреннән саналган Алсу, Чулпан, Ирек кебек исемнәрнең бөтен дөньяга танылуы да исем сайлавына йогынты ясый.

## *Исем кушу тәртибе*

Балага исем кушуның үз тәртибе бар. Иртән, иң әйбәте кояш чыкканда, баланың ата-анасы, әби-бабасы, якын туганнары һәм барлык кардәш-ырулары бәйрәм мәҗлесенә җыела. Баланы яхшылап юындыралар, чиста биләүләргә төреп, йөзен көнчыгышка каратып, мендәр өстенә салалар. Сабыйга исем кушучы аның баш очына каршы баса, көнчыгышка карап дога (арбау) әйтә:

*Атың Яшәр булсын, бишек бавың нык булсын!*
*Артыңда кече, алдыңда олы кардәшләрең булсын!*
*Бишек бавың купмасын, арт итәкләреңне*
*мал-мөлкәт, алгы итәкләреңне балалар бассын!*
*Аксакал кебек ак сакаллы, нык тешле бул!*
*Ак тешләрең саргайсын, кара чәчләрең агарсын!*

Бу доганың соңында мөселман татар-төркләр “амин”, ә Тәңре динен тотучылар утка май сибеп, “опкоруй!” дияләр.

Арбауның тәүге юлында мисал өчен “атың (исемең) Яшәр булсын” диелә, әлбәттә башка исем дә кушылырга мөмкин. Һәр гаилә, һәр нәсел яңа әгъзасының исемен үзе сайлый.

Күрүебезчә, бу дога балага бәхетле озын гомер теләүдән гыйбарәт. Бәхетле булу – мул тормышта күп бала үстерүдер. Ишле гаиләсе булганда гына кеше озак, ягъни тешләре саргайганчы, чәчләре агарганчы яши бит.

Бала бәхетле булсын өчен исем кушу йоласын дөрес үткәрү шарт. Әгәр балага гарәп-фарсы исемен кушсагыз, мулланы чакырыгыз, ул мөселман догасын укыр, исем бирү мәҗлесен гарәпләр һәм фарсыларның гореф-гадәтләре буенча үткәрер. Балага христиан дине белән бәйле исем кушылса, попны (батюшканы) чакыру дөрес булыр. Ә менә балага саф татар исемен бирергә ниятләсәгез, кемне чакырырга? Сезнең нәселегездә, туганнарыгыз арасында акыллы, белемле һәм ихтирам ителгән әйдәп баручы шәхес бардыр. Һәр нәселнең

телгә оста булган, дәрәҗәле бер лидеры бар. Бала туу белән ул нәсел арта, ишәя һәм балага исем бирү дә, әлбәттә, шул кешегә, ягъни нәсел (ыруг) башлыгына[1] йөкләнә. Гадәттә ул өлкән яшьтәге кеше, ягъни карт була. (*Карт* сүзе иске татар телендә яшь күрсәткече генә түгел, ул шулай ук нәсел башлыгы дигән мәгънәне дә үз эченә алган). Карт мәҗлескә пакъ тәнле булып, матур, чиста киемнәрдә килә. Тиешле татар догасын ул алдан ук өйрәнеп, белеп тора. Исем бирелгәч, теләкләр тели:

*“И, Тәңрем! Бу бала татар милләтен куәтләүче, иленә-җиренә тугрылыклы, ата-анасына игелекле, шәфкатьле бала булсын. Ата-анасы тәрбиясендә сәламәт булып үссен. Нәселебезне ишәйтсен, бәхет-дәүләткә ирешсен”.*

Мәҗлестә утыручы ата-анага һәм башкаларга балаларны гадел, батыр, тәүфыйклы итеп үстерүнең җаваплылыгы, аларны милли рухта тәрбияләү бурычлары аңлатыла. Болардан соң исем бирелгән балага багышлап “Бәхет-дәүләт” догасы укыла.

Исем кушу – картның (нәсел башлыгының) мактаулы, күркәм вазыйфасы. Димәк, бу ыруг-нәселдән булган дистәләгән, бәлки йөзләгән кеше аны олылый, араларында иң дәрәҗәлесе дип таный. Бер үк вакытта, бу йолада башлап йөреп, ул үз өстенә зур җаваплылык та ала. Яңа туган баланың атасы һәм анасы белән беррәттән, ул аны кайгыртырга, кирәк булса, ярдәм итәргә дә тиеш. Әле бүген дә Тәңре динендә яшәүче алтайлыларда ул нәкъ шулай. Алар тормышында ыруг механизмнары саклана, туганлык әле онытылмаган, аның белән бәйле мәсьәләләр уйланган, көйләнгән. Мәсәлән, бала ятим калырга мөмкин. Бездә бала ата-анасыннан башка беркемгә дә кирәкми, алар вафат булса, бала детдомга (балалар йортына ), ягъни дәүләткә тапшырыла. Алтайлыларда ятим калган бала язмышын бөтен туганнары кайгырта, чөнки ул ата-ана баласы гына түгел,

[1] Нәсел (ыруг) башлыгы – *(рус.)* старейшина

ул әле ыруг әгъзасы да. Нәсел башлыгы (лидеры) барлык туганнарны җыя. Гадәттә, зур җыенда бу нәселгә караган бер гаилә ятим калган баланы үзенә ала. Алырга теләк белдерелгәч тә, шундук ризалык бирелми әле. Озак киңәшләшәләр, баланы алырга ниятләгән гаиләнең мөмкинлекләрен карыйлар. Нәсел башлыгы тәрбиягә алынган баланың ничек яшәвен күзәтеп, контрольда тота.

Исем кушу йоласын үзебезчә оештырганда, күрше карчыклар җыелмый инде. Бу мәҗлес ыруг бәйрәменә әверелә, шуңа күрә туган-тумача җыелырга тиеш. Якын һәм бигүк якын булмаган кардәшләр, йолада катнашып, бала өчен булган җаваплылыкны ата-анасы белән бүлешәләр, ярдәм кулы сузарга вәгъдә итәләр. Менә йоланың мәгънәсе.

Нигә исеменә күрә рухание да, догасы да булырга тиеш соң? Һәр исем билгеле бер дөньяга, дөресрәге культурага карый, ягъни мәсәлән, ислам дине белән бәйле исемнәр – гарәп-фарсы дөньясына (цивилизациясенә), христиан исемнәре – рус һәм Аурупа (Европа) культурасына, саф татар исемнәре – төркләр (төркиләр) мәдәниятенә. Альберт, Луиза кебек исемнәр белән балалар Аурупа-христиан дөньясына кушылып китә, ул культураның вәкаләтле вәкиле (рухание) балага шуның ишеген ачып, кертеп җибәрә. Исем үзе йола вакытында пароль функциясен үти. Парольне дөрес әйткәч, тиешле ишек ачыла һәм бала сайлап алынган культурага, цивилизациягә кушылып китә.

## *Нигә татарларның фамилияләре юк?*

Кешегә эндәшү, атап мөрәҗәгать итү өчен исем белән беррәттән фамилия дә кулланыла. Исем аерым бер кешене, ә фамилия аның кайсы нәселдән булуын күрсәтә. Бүгенге татарларның фамилияләре юк. Әлбәттә, татарлар да нәселсез, җилдән туган халык түгел. Аларның да нәсел-ыруг атамалары бар, элек, татарның күпчелеге әле авылларда яшәгәндә, нәсел

исемнәре кулланышта иде. Авылда һәр кешенең исеме һәм фамилиясе була. Авылдашлар бер-берсен, мәсәлән, Бүре Сәлиме, Шәҗәрә Гөлҗиһаны йә Аю Наиле дип йөртәләр иде. Соңрак татарның үзенә хас һәр нәрсә искелек калдыгы дип табылды, шул җөмләдән нәсел исемнәре дә кушамат дип мыскыл ителә башлады. Чынлыкта исә нәсел исемен белдергән кушаматта бернинди дә кимсетү юк. *Фамилия* сүзе чит телдән килгән һәм нәсел исемен аңлата. Ул сүзнең татарчага тәрҗемәсе *кушамат* була. Украинча да ул нәкъ шулай – алар фамилия димиләр, *прізвище* диләр. *Прізвище* – прозвище, кушамат. Кушаматларыбызга махсус рәвештә тискәре караш тәрбияләнде. Әлбәттә, ул юкка гына эшләнмәде – максат татарны татарлыгыннан, үз культурасыннан биздерү, үз тамырларыннан аеру иде. Бу мәкерле сәясәт уңышка иреште, татарлар нәсел исемнәреннән баш тартып, фамилия урынына бабалары исемнәрен куллана башладылар. Бүре Сәлимнәре, Аю Наилләре һ.б. авылда калды, шәһәргә Абдуллиннар, Миңнуллиннар, Идрисовлар һ.б. күчеп килде. Татарның үз нәсел-ыруг атамалары онытылды. Әйтик, киң таралган “Абдуллин” фамилиясендә иясенең татарлыгын чагылдырган берни дә юк. Ул *абдулла*, ягъни *Аллаһ колы* дигән гарәп сүзенә рус теленнән алынган *-ин* кушымчасын өстәп тудырылган.

Татарлар үз кушамат-фамилияләреннән баш тартсалар да, ул кушаматлар татардан чыккан русларда яшәп килә. Русларда Абашев, Адашев, Акишев, Акчурин, Алаев, Балакирев, Башмаков, Ермолов, Каратай һәм башка чын татар фамилияләре еш очрый. Мисал буларак әйтик, саф татар фамилиясен йөртүче Павел Бүре – дөньяга танылган спортчы. Белорус шагыйре Александр Каратай да күпләргә таныш. Ә менә фамилияле татарлар бик аз. Габдулла Тукай белән Бакый Урманчы гына искә төшә. Дөрес, Алтынбаевлар, Сәйдәшевләр, Хановлар һ.б. да бар, ләкин аларның фамилияләре, татар нигезле булса да, рус теленә яраклаштырылган.

Кешегә эндәшү, мөрәҗәгать итү өчен исем һәм фамилия-кушамат хезмәт итә, дигән идек. Алар *антропонимик категорияләр* дип аталалар. *Антропонимика* – тел белеменең кешеләрне атау берәмлекләрен өйрәнүче махсус тармагы. Рус телендә ике төп антропонимик категория булган исем вә кушаматка өченчесе өстәлә – отчество (ата исеме). Алар, мәсәлән, Зайцев Иван Васильевич, диләр. Күпчелек башка халыклар ике антропонимик категория белән канәгатьләнә. Аларның Вильям Хьюитт, Дэвид Понд, Ричард Вебстер, Стефен Кауфман, Туран Язган кебек исем-фамилияләрен еш ишетәбез. Татарлар берәр мөгез чыгарырга оста. Фамилия-кушаматларыннан ваз кичеп, алар дүртенче антропонимик категория – бабайлары исемнәрен дә керттеләр. Мисал: Абдуллин Рәшит Камилевич булып йөрүче татар кешесенең үз исеме Рәшит, атасы исеме Камил, бабасы Абдулла. Бу кешенең фамилиясе (нәсел исеме) төшеп калган. Фамилия җиренә бабай исеме баскан. Абдулла бабайның исеме “Чей, из какого рода?” дип русча бирелгән сорауга җавап булып тора – “Абдуллин”. Сакланып килгән кайбер чын татар фамилияләре дә бүген шул ук сорауга русча җавап кайтара: Алтынбаев, Сайдашев, Ханов һ.б. Нигә мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшевне үзебезчә Салих Сәйдәш дип йөртмибез? “Сәй” – борынгы төрки-татар сүзе, нәселне аңлата. Төрек телендә ул сүз “сой” буларак сакланган. “Сәйдәш”, “сойдаш” – нәселдәш димәк. Татар әдәбияты, сынлы сәнгате һәм музыкасының өч терәге булган Габдулла Тукай, Бакый Урманчы һәм Салих Сәйдәш үз фамилия-кушаматларын кадерләп саклаганнар.

Тагын бер хикмәт. “Чей, из какого рода?”, ягъни “Кайсы нәселдән?” дигән сорауга татарлар бүген русча “Галиуллин, Миннуллин, Идрисов” кебек җаваплар бирә, ә менә кыпчак халкыннан чыккан һәм хәзерге заманда үзләрен славяннар дип санаган украиннар “Фамилияң ничек?” диючегә кыпчакча (төркчә) “Степаненко” дияргә мөмкин. Степаненко –

Степанныкы инде ул, әзрәк бозылган гына. Украиннарның бик күп фамилияләре саф төрки сүзләр (Барабаш, Бульба, Гоголь һ.б.), алар аша борынгы кыпчак телен өйрәнергә була. Кызганыч, ул бәйләнешләрне тикшерүчеләр генә юк. Тел белгечләребез бәйләнешләрне түгел, ә диалектик аермаларны барлый, аңлапмы-аңламыйчамы халкыбызны бүлүгә хезмәт итә...

Элек кешеләр табигать белән гармониядә яшәгәннәр, табигатьтәге әйберләрнең һәм күренешләрнең үзенчәлекләрен, серләрен яхшы белгәннәр. Алар табигатьне, аның камиллегенә сокланып, хәтта илаһилаштырганнар. Нәтиҗәдә, төрле мәҗүси ышанулар, дини карашлар барлыкка килгән. Борынгы кешеләр бигрәк тә тере табигатьне тәшкил иткән хайваннарга, кош-кортларга, балыкларга һ.б. сокланганнар. Сокланып кына калмаганнар, аларның күркәм сыйфатларын да үзләштерергә тырышканнар. Билгеле бер нәсел яки ыруг, кабилә аерым бер хайван рәсемен кабилә тамгасы итеп алган, шул тамганы мал-мөлкәтенә төшергән, ташларга уеп ясаган. Шул хайваннарның исеме белән аны олылаган нәсел яки ыруг аталган. Менә шуңа, буыннан-буынга күчеп, нәсел-ыруг атамалары функциясен башкаручы борынгы кушаматларда хайван, кош-корт һәм үсемлек исемнәре еш очрый. Әле хәзер дә татар авылларында Әтәч, Каз, Тавык, Чыпчык, Акчарлак, Карга, Чәүкә, Торна, Ябалак, Аю, Бүре, Кәҗә, Бурсык, Чуртан, Ясмык, Арпа һ.б. кебек нәсел атамалары сакланганнар. Һәр нәселнең үзенә генә хас бер шөгыле, һөнәре, осталыгы да булган. Кайбер кушаматлар шул шөгыль-һөнәр исемнәреннән чыккан: Акчура, Алпар, Баскак, Игенче, Сабанчы, Сунарчы, Табакчы, Тылмач һ.б. Мондый фамилия-кушаматлар бүгенге төрекләрдә күп. Мәсәлән, Сабанчылар – Төркиянең мәшһүр байлары, ләкин аларның да нәселләре оста сабанчылардан килә. Бакый ага Урманчының нәселендә урманчылар булгандыр. Нәсел исемнәре башка юллар белән дә барлыкка килгән һәм элек кадерләп сакланган. Башка

халыкларда изгеләштерелгән, буыннан-буынга олы мирас итеп тапшырылып килгән кушаматларны татарның наданнары эт-мәчегә бирә башлады. Татар совет язучылары бу наданлыкны әдәби әсәрләр аша ишәйтте, нәсел исемнәрен мәсхәрәләүгә зур өлеш кертте...

Менә шундый аяныч хәлләр. Әгәр бүгенге татар фамилияләре турында төптән уйлансак, күңелләребезгә борчу тула. Исем-фамилия милләтнең йөзе, дибез. Кызганыч, бүгенге исем-фамилияләребездә миллилек аз калды. Ләкин өметсезлеккә бирелергә ярамый. Без бит искиткеч рәхәт, демократик заманда яшибез. Чын исем һәм фамилияләребезне кайтарыр өчен хөкүмәт карары кирәкми. Андый карарны һәркем үзе бирә, бу шәхси эш. Яңа туган балаларга матур татар исемнәре бирик, татарлыгыбызны яшермик. Бер җиребез дә гарәплләрдән яки аурупалылардан ким түгел. Татарлар читтән килгән исемнәргә кызыкмыйча, үз исемнәрен йөртсен иде. Ә инде фамилияле булырга, нәсел атамаларын кайтарырга теләүчеләргә гражданлык хәлен теркәүче органнарга (ЗАГС ларга) мөрәҗәгать итәргә генә кирәк. Закон буенча, һәр кеше үзе теләгән фамилияне алырга мөмкин, ул аны үз теләге белән алыштыра да ала. Соңга калмыйк, нәсел исемнәребезне белгән картлар берәм-берәм бу фани дөньядан китеп бара. Үз фамилия-кушаматларыбызда безнең телебез һәм тарихыбыз. Аларны кайтару – изге гамәл, нәселебездәге барлык ата-бабаларыбызны олылау.

“Оренбург мөселман диния нәзарәте 1894 елның 13 мартында исемнәр турында махсус циркуляр чыгара (№ 1886) һәм гамәлгә ашыру өчен мәхәллә имамнарына җибәрә. Бу циркулярда мәхәллә имаманарына, муллаларга яңа туган балаларга нинди исемнәрне кушмаска, нindиләрен кушарга кирәклеге турында күрсәтмә бирелә”, – дип яза Гомәр Саттар-Мулилле үзенең “Татар исемнәре ни сөйли? (Татар

исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге)” дигән китабында[1]. Татар балаларына төрки-татар чыгышлы исемнәр кушу тыела. Ул гына түгел, хәтта милләтебезгә хас булган *асыл, иш, бик, бикә, бай, тимер, мирза, хан* һ.б. антропонимик компонентлар ялганып ясалган кушма исемнәрне дә бирмәскә кушыла. Татар балаларына Аллаһ исемнәренә *габде-абде (кол)* сүзе кушылган Габдулла, Габдрахман, Габделрәхим һ.б. кебек исемнәрне генә бирергә рөхсәт ителә. “Муллаларның исемнәребездә ни эшләре бар, аларны кем тыңласын инде?!”, – дияргә ашыкмагыз. Бу циркуляр хөкүмәт карары көченә ия булган бер документ. Ул чорда дин дәүләттән аерылмаган әле, балаларга бирелгән исемнәрне теркәүче ЗАГС органнары да юк. Бу вәкаләт элек заманда дәүләттән эш хакы алып хезмәт итүче дин әһелләренә бирелгән. Оренбург мөселман диния нәзарәте чынлыкта татарның бөтен тормышын диярлек контрольдә тоткан дәүләт органы булган. Күрүебезчә, элек татарларның газиз балаларына үзләре яраткан милли исемнәрне бирү мөмкинлеге булмаган, аларга *кол* сүзе кушылган гарәп исемнәрен йөртү боерылган...

Инде шөкер, халкыбызны җәберләүләр үткәндә калды. Бүген һәр нәрсә безнең үз кулыбызда. Без ямьле дөньяда бәхетле чорда яшибез.

## *“Татар исеме булмый, кем исеме булсын тагын?..”*

“Безнең исемнәребез милли асылыбызны, халык буларак үзенчәлегебезне , милли горурлыгыбызны, камил зәвегыбезне, кыскасы, мөстәкыйль йөзебезне чагылдырамы?” – дигән сорау куя танылган татар галиме, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Нурмөхәммәт Хисамов “Мәдәни җомга” гәҗитендә басылган бер мәкаләсендә һәм җавабын да бирә: “Әлбәттә, чагылдыра. Дөресрәге, тарихи, этник, иҗтимагый халәтебезне күрсәтеп тора, милли йөзебезне югалта баруыбызны гәүдәләндерә”. Нигә

---

[1] Кара: 23 нче бит

бүген татарлар балаларына үз телennән үсеп чыккан исемнәрне аз кушалар? Бу кимчелек тойгысыннан киләдер. Күпләр үзен гарәпләрдән яисә европалылардан түбән күрә. Татар кешесе башка халыклардан килгән исемнәрне алып, татарлыгыннан кача. Баласын "Роберт" дип атап, аны европалы иттерәсе килә, аның татар булуын белмәсеннәр иде, ди. Менә нидә хикмәт! Кем ул Роберт исемен йөрткән зат, кайсы милләт баласы? Инглизме, алманмы, французмы яки русмы? Бу исемнең татар кешесенә хас милли йөзе, төсе, сыйфаты һич юк. "Йөзеңне яшерү ул асылыңның, җаныңның пакъ булмавын күрсәтә, – дип дәвам итә Нурмөхәммәт Хисамов шул ук язмасында. – Илнең иҗтимагый фикерендә шовинистик тарих дәреслекләре һәм дәүләтнең шундый ук сәясәте нәтиҗәсендә татарга карата хөкем сөргән начар мөнәсәбәт милли горурлык, гореф-гадәт һәм әхлак йолаларын югалткан милләттәшләребездә әнә шулай чит халыкка хас исемнәр белән йөзен яшерү кебек иләмсез күренешне барлыкка китерде". Кызганыч, татарның үз исеменнән оялу, уңайсызлану кебек рухи халәте бүгенге көнгә кадәр сакланып килә...

Үзләрен уйлану, эзләнү мәшәкатеннән бөтенләйгә азат иткән кайбер ата-ананың кыланышларына шаккатасың. Бер танышым улын "Альберт" дип йөртә. Мин аның баласында чит исем икәнен әйткәч, гаҗәпләнеп: "Ул татар исеме булмый, кем исеме булсын тагын?!" – дип куйды. "Альберт" сүзенең безне, түрк-төркиләрне, еш кына дошман күргән греклар сүзе булуы бичараның башына да килмәгән. Әйе, бу чит сүзне татарлар балаларына исем буларак еш куллана. Шуңа "Альберт" – татар исмеме? Соң алайса яңа татар байлалары яратып кулланган "Тойота" җиңел машинасы да японныкы түгел, ә татарныкымы?!

Сугыш алласы "Марс" та татарда популяр. Әллә бала сугыш чукмары булсын дип кушыламы бу исем? Веналар да күп бездә. Грек-юнан мифологиясеннән бу исемнәр. Венера –

мәхәббәт алиһәсе. Мәдәни халыклар балаларына алла исемен кушмыйлар. Алдынгы Аурупа халыкларында “Венера”лар юк. Бәлки, татар кешесенә бу сәер гадәт гарәпләрдән килгәндер – аларда Аллаһы Тәгаләнең 99 күркәм исемен кешеләргә дә кушу гадәте бар бит...

Киң таралган кайбер башка исемнәргә дә күз салыйк инде. Менә “Альбина”, шулай ук татар сүзе түгел, латин теленнән килгән сүз, ак төсне аңлата. “Артур” сүзе кельтләрдән, мәгънәсе “куәтле аю”. Кызлар исеме буларак кулланылган“Лениза” – “Ленинские заветы”, ә татар ир баласына куша торган “Ленар” исеме “ Ленин армиясе” сүзләреннән ясалган. “Вилдан” – “Владимир Ильич Ленинга дан!”нан килә, ә “Ренат” революция, наука, труд сүзләреннән, “Рэм” – революция, электрофикация һәм механизациянең баш хәрефләреннән ясалган исемнәр. “Празат” исеменең чыгышы да кызык, ул пролетариат азатлыгын даулаган чорда туган. “Луиза” иске француз теленнән, данлы сугышны, бәрелешне аңлата. Чын татар исеме булып саналган “Сания” чынлыкта гарәп теленнән килә, секундны белдерә. “Рәзил” – шулай ук гарәпчәдән, түбән, хур, начар димәк. “Күп саташтырдык рәзил шайтанны чын инсан белән”, – дип яза Габдулла Тукай. “Рәдиф” – гарәпләрдә берәүгә ияреп баручы, арттан йөрүче, ә рәкыйп дип гарәпләр көндәш, конкурент турында сөйлиләр. Бәлки, татарлар бер-беренә тикмәгә генә дошман-рәкыйп түгелләрдер?..

Татарлар кулланган исемнәр буенча берничә китап авторы Гомәр Саттар-Мулилле: “Һәркемгә үз исеме – күңеленә иң якын, иң кадерле исем-сүз”, – дип яза. Нәкъ шулай. Милләттәшләребез үз телен, үз исем-сүзләрен күңеленә якын итсен, кадерләсен иде. Татар кешесе дә үз баласына исем куйканда куштанлыктан, тәкәбберлектән, карьерадан һәм башка барлык вак исәпләрдән өстен булырга тиеш. Балага ат-исем сайлаганда җитди булыйк, кыска гомерле модага иярмичә эш итик. Балага исем, ул күркәм сыйфатларга ия булсын иде, дигән теләк белән кушыла. Исем

белән җисем тыгыз бәйләнештә торалар. Кеше исеме аны йөртүче шәхеснең асыл сыйфатына әверелә. Башка халыкларда эт баласына исем кушканда да уйланалар, сорашалар, киңәшләшәләр. Татар кешесе генә мәгънәсен аңламаган чит бер сүзне үз баласына исем итеп чәпәп куяла...

Исемнәр җыелган китапларда һәр исемнең мәгънәсе һәм кайсы телгә каравы язылган. Теләгәнеңне сайлап алу гына кала. Кайберәүләр, христиан яисә мөселман диненнән бәйсез рәвештә туган, чит телләрдән кермәгән ягымлы татар исемнәре бик аз, диләр. Бу сүзләрнең дөреслеккә туры килмәвен күрсәтер өчен генә биредә халкыбызның үз рухи хәзинәсе, үз теле белән бәйле булган кайбер ир-ат вә хатын-кыз исемнәре бирелгән. Борынгыдан килгән затлы һәм халыкчан исемнәр милләтебезнең килчәгенә ышаныч тудыра, күңелләрне сөендерә, хушландыра...

# ТАТАР ИСЕМНӘРЕ

## *Бәхет китерүче ир-ат исемнәреннән үрнәкләр*

## А

**Аба** өлкән ир туган. Бу исем беренче булып туган ир балага бирелә

**Абай** оста, һөнәрле олкән кеше

**Абак** табына торган сурәт, сын

**Абыз** дәрәҗәле, тәҗрибәле

**Абызбай** тәҗрибәле бай

**Аван** яхшы күңелле кеше

**Агабай** өлкән бай

**Агабәк** ил агасы

**Агахан** ага хан

**Агдәл** ак күңелле кеше

**Агиш** ак иш (дус, тиң)

**Агычы** хәзинәче

**Адал** яхшы исемең танылсын, дан казан

**Адалан** ат-исеме танылган, дан казанган

**Адар** данлы ир

**Адыкөн** исеме якты, көн кебек булган кеше (көндез туган балага бирелә)

**Аеш** ай ише

**Аҗа** бөек; көчле

**Аҗар** көчле, нык, сәламәт ир

**Аҗарбай** көчле һәм бай кеше

**Аҗарман** тиз уңышка ирешүчән кеше

**Аҗарсой** көчле нәселдән

**Аҗунбай** дөньяның бай кешесе

**Азак** соңгы, төпчек бала

**Азалак** яраткан кеше (бала)
**Айбай** ай кадәр матур һәм бай
**Айбак** ай сыман бала бак (кара, ту)
**Айбакты** ай кебек чибәр бала туды
**Айбар** кешедә хөрмәт уяткан, күркәм
**Айбарс** ай кебек гүзәл, барс кебек җитез. Һун императоры Атилланың агасы исеме
**Айбаш** ай башында туган ир бала
**Айбәк** ай сыман матур бәк, белемле җитәкче (*русча синонимы*: князь)
**Айбирде** ай кебек чибәр бала бирде
**Айбуга** ай төсле матур, буга (үгез) сыман көчле
**Айбул** ай сыман чибәр бул
**Айбулат** ай кебек чибәр, булат корыч кебек нык
**Айбүләк** ай кебек күркәм бала (*бүләк* сүзе кергән исем туганчы ук әтисе үлгән балага кушыла, *әтисе бүләге* дигән мәгънәгә ия)
**Айтаҗ** ай таҗы, айга таҗ булган
**Айгына** нәкъ ай кебек
**Айдай** айдай, ай шикелле
**Айдак** айлы, ае бар
**Айдан** абруйлы, дәрәҗәле
**Айдар** дәрәҗәле, билгеле
**Айдарбәк** ай сыйфатларына ия булган бәк
**Айдархан** ай сыйфатларына ия булган хан
**Айдаш** ай кебек
**Айдын** яктылык, нур чәчүче; белемле
**Айъегет** ай кебек нурлы егет
**Айкай** үзен ай иркәләгән кеше
**Айкан** аксөяк, затлы нәселдән; намуслы
**Айкач** акыл бирүче; оратор; шагыйрь
**Айкут** бәхетле; бүләк
**Айкын** ачык, анык, билгеле; җитез, хәрәкәтчән

**Айман** ай кебек гүзәл
**Айнур** ай нуры
**Айсан** ай кебек, ай йөзле
**Айсар** ай кебек алтынсу сары
**Айсин** син ай сыман
**Айсөяр** ай сөяр
**Айсу** ай һәм су кебек
**Айташ** ай кебек матур һәм таш кебек нык, таза; ай ташы, асылташ
**Айтәкин** ай принцы, ай шаһзадәсе
**Айтимер** ай кебек нурлы, якты тимер
**Айтирәк** ай кебек күркәм, нык тирәк
**Айтуар** ай кебек матур бала туар
**Айтугай** айлы тугай
**Айтуган** ай сыман ир туган
**Айтулы** тулы ай вакытында туган
**Айхан** нурлы хан
**Айчуак** ай кебек якты һәм аяз
**Айчура** ай кебек батыр сугышчы
**Ак** күркәм сыйфатларга ия
**Акаҗун** ак, мәрхәмәтле дөньяда яшәүче
**Акай** ай ялтырап торган чорда туган
**Акалтын** платина, ак төсле алтын
**Акасой** билгеле, танылган нәселдән килүче
**Акат** яхшы исеме танылган
**Акбай** хәләл мал җыйган бай
**Акбарс** ак барс сыман кеше
**Акбату** курыкмас ир-ат
**Акбатыр** ак батыр, яхшы күңелле батыр
**Акбаш** башында ак уйлар йөртүче (ак чәчле ир балага кушыла)
**Акбәк** ак бәхетле бәк (башлык, түрә, *рус.* князь)
**Акби** күркәм би (башлык, түрә, *рус.* князь)
**Акбилгә** белемле, галим кеше

**Акбит** ак йөзле, пакъ күңелле

**Акбуга** ак бәхетле һәм буга (үгез) кебек көчле кеше

**Акбулат** ак бәхетле һәм булат корыч кебек нык кеше

**Акбүләк** ак, яхшы, асыл бүләк (әтисе үлгәннән соң туган балага бирелә торган исем)

**Акгирай** озын гомерле ир

**Акдар** кадерле кеше

**Акҗегет – Акъегет** ак, изге күңелле, намуслы егет (*рус.* Акджигит)

**Акир** ак тәнле, чибәр ир

**Аккөн** ак, шатлыклы көн

**Аккөч** файдалы, дошманны җиңүче көч

**Аккылыч** ак бәхетле һәм кылыч кебек үткен кеше

**Аккына** ак, яхшы сыйфатларга гына ия булган кеше

**Акланыш** акланыш, аклау (бала таба алмый дип саналган килен ир бала тудыргач кушыла)

**Аклаш** аклаучы

**Акман** ак, матур кеше (гыйнвар аенда туучы балага бирелә)

**Акманай** акман аенда туучы (төрки телдә гыйнвар аеның атамасы)

**Акморат** изге теләк

**Акморза** ак бәхетле морза (башлык, җитәкче, түрә)

**Акпулат** бәхетле башлык, хөкемдар

**Аксан** әйбәт һәм бик танылган кеше

**Аксой** ак, затлы нәселдән

**Аксөяк** аксөяк, аристократ

**Аксын** ак сынлы, ягъни аристократ

**Аксубай** ак бәхетле гаскәр башы

**Актаҗ** ак таҗ иясе

**Актай** ак төс иясе, ак төстәге

**Актанай** таңгы ай, таңгы айга тиң

**Актаң** күк читендә аклык күренеп, таң атканда туган балага кушыла

**Актар** якты иртәдә туган
**Акташ** мәрмәрташ кебек нык
**Актәкин** ак принц, бәхетле шаһзадә
**Актимер** ак бәхетле, тимер кебек нык
**Актирәк** актирәк изге агач дип санала
**Актуган** ак (изге, яхшы ниятле) туган
**Актук** ак (изге, яхшы ниятле) һәм тук (бәхетле) кеше
**Акул** ак, матур ул (угыл)
**Акурак** ак бәхет китерүче
**Акхан** ак бәхетле хан
**Акһун** бәхетле һун нәселеннән
**Акчалы** бай, акчасы күп булган
**Акчуак** чуак (аяз, кояшлы) көнне туган балага гомер юлы аяз, бәхетле булсын дип кушыла
**Акчулпан** таң йолдызы сыман ак
**Акчура** бәхетле батыр сугышчы (баланың хәрби кеше булуын теләп кушыла торган исем)
**Акшит** котлы, бәхетле; нур, кояш
**Акъюл** туры, дөрес, яхшы юлда йөрүче
**Акъяр** ак, саф күңелле дус
**Алай** бу исемне балаларына хәрбиләр бирә, алай – полк димәк
**Алан** яхшы күңелле
**Албай** 1. ал бай; 2. гаскәр башы
**Албарс** алып барс, баһадир барс
**Алгай** тәүге ир бала
**Алгыр** алдынгы, җитез, өлгер
**Алдан** гаиләдә беренче булып туучы ир бала
**Алкын** булган, уңган
**Алмас** явыз көчләр, чирләр бу баланы алмас, аңа тимәс
**Алмасхан** болгар ханнарының берсе
**Алматай** алмалы тай
**Алмаш** алмашка килүче
**Алпагыт** батыр, көчле кеше

**Алпак** тимер башлык, хәрби kием
**Алпар** рыцарь (*алып* һәм *ар, әр, ир* сүзләреннән)
**Алтай** урман белән капланган тау, алтын тау
**Алтаң** ал таң
**Алтын** затлы, кыйммәтле
**Алтынай** алтын ай
**Алтынбай** алтын бай
**Алтынбәк** алтын бәк
**Алтынби** алтын би
**Алтынбулат** алтын булат
**Алтынгәрәй** алтын гәрәй
**Алтынкай** алтын кебек кадерле
**Алтынсары** алтынсу сары төсле
**Алтынташ** алтын таш
**Алтынтимер** алтын тимер
**Алтынчура** алтын чура
**Алчак** шаян, сүзчән, хәйләкәр
**Алчын** бәхетле, бәхетле өлеш
**Алчынбай** бәхетле бай
**Алып** алып, баһадир, рыцарь
**Алыпарслан** баһадир арслан
**Алыптай** алыптай, алып кебек
**Аман** 1. сау, сәламәт, таза; 2. саф, файдалы, шифалы; 3. дөрес, гадел, аек
**Аңкилде** аң килде
**Апанай** *апа* (өлкән туган) сүзенә *–най* иркәләү кушымчасы ялганып ясалган борынгы исем
**Аппак** ап-пак, бик саф, керсез
**Аргамак** аргамак, чабышкы
**Ардак** кадерле, хөрмәтле
**Ардаш** арадаш (беренче баладан соң шактый вакыт узгач кына туган икенче ир балага кушыла торган йола исем)
**Арслан** арыслан

**Арсланбай** арысландай көчле бай
**Арсланбәк** арыслан кебек кыю бәк
**Арслангәрәй** арыслан гәрәй
**Арсланхан** арыслан кебек кыю, көчле хан
**Артукач** *артык* (чамадан тыш) сүзенә *-ач* иркәләү кушымчасы өстәп ясалган исем. (Күп балалы гаиләләрдә башка бала булмасын, дигән теләк белән бирелгән йола исем)
**Артык** артык бала. (Ишле гаиләдә яңа туган ир балага кушылган йола исем)
**Артыкбай** артык бай
**Артыш** 1. артыш, күбәеш; 2. артыш агачы
**Арчан** мәңге яшел куак
**Арык** таза, саф
**Аслан** арыслан
**Асыл** 1. асыл, төп; 2. асыл, чын
**Асылбай** асыл бай
**Асылбәк** асыл бәк
**Асылгәрәй** асыл гәрәй
**Асылхан** асыл хан
**Ата** 1. ата, өлкән, хөрмәтле; 2. алдынгы, әйдәп баручы
**Атабай** ата бай
**Атабәк** ата бәк
**Атак** дан, шөһрәт
**Атахан** ата хан
**Атилла** Идел кешесе, Иделле (Идел елгасының борынгы исеме булган *"этил"* сүзеннән). Бу исем венгрларда да киң таралган
**Атыяз** аты (исеме) яз (*рус.* Атияз)
**Ачи – Ачы** ачы тәмле (сабыйны яман көчләрдән саклау максаты белән кушыла)
**Ашан** бүре ыругыннан чыккан князь (*рус.* Ашина)
**Ашмас** үлмәс
**Ашыт** *ашин* (бүре) ыругы атамасыннан

**Аю** аю

**Аюбәк** аю кадәр көчле бәк

**Аюби** аю кебек көчле би

**Аюкай** *аю* сүзенә *–кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы өстәлгән

**Аюкач** *аю* сүзенә *–кач* иркәләү кушымчасы ялганган

**Аюташ** аю таш (бу исем ир балага аю кебек көчле һәм таш кебек нык булсын дигән теләк белән бирелә)

**Аюхан** аю хан

**Аючы** аю биетүче

**Аяз** аяз, болытсыз (баланың гомере якты, бәхетле булсын дип кушыла)

# Б

**Бабахан** баба – ата, өлкән хан

**Бабич** бәбәч, кечкенә бала

**Бабур** Төркистанда яшәгән бер каплан[1] төре. Бөек Могол дәүләтен төзегән хөкемдар исеме

**Багыш** ата-анасын картлык көнендә караучы (багучы)

**Бадак** зур белемле

**Бадакхан** гыйлемле хан

**Бадакшан** зур белем, шан иясе

**Баек** анык билгеле, тәгаен

**Базарбай** базар көнне туган бай

**Бай** куәтле, киң мөмкинлекләргә ия булган бай кеше

**Байарслан** бай арыслан

**Байбак** далада яшәүче җәнлек

**Байбарс** бай барс (юлбарыс)

**Байбатыр** бай батыр

**Байбул** бай бул (бу исем баланың бай булуын теләп кушыла)

**Байбулат** бай булат

---

[1] Каплан – барс, леопард

**Байбулды** бай булды (туды)
**Байбулсын** бай булсын (баланың бай булуын теләү)
**Байбура** бай бура (ата дөя)
**Байбәк** бай бәк (князь)
**Байбүләк** 1. бай бүләк (атага ир бала); 2. атасы үлгәч туган бала, этисе бүләге
**Байбүре** бай бүре (йола исеме: әгәр бала тешле булып туса, яки аңа, киресенчә, озак тешләр чыкмаса, *бүре* сүзе кергән исемнәр бирелә)
**Байгелди – Байкилде** бай килде (туды)
**Байгура** бай һәм саран кеше
**Байгына** бай гына булачак ир бала
**Байгыш** мәче башлы ябалак
**Байгәрәй** бай гәрәй
**Байдар** байлык иясе
**Байдык** байлыкка ирештек (ир бала туганга сөенеп кулланылган исем)
**Баеш – Баиш** бай иш
**Байкал** бай күл
**Байкара** бай кара (теләк исем: бай бул, бай булып ту)
**Байкотлы** бай (мул, тулы) бәхетле
**Байкучат** бай кучат (әтәч)
**Байкучкар** бай кучкар (тәкә)
**Байкуәт** бай куәт, куәтле бай
**Байкылыч – Байгылыч** бай кылыч (дошманнарына карата үткен кылыч сыман булсын дигән теләк белән бирелә)
**Байкөчек** бай көчек
**Байкүбәк** бай күбәк (1. корал көпшәсе, хәнҗәр сабы; 2. тотка, тоткыч)
**Баймак** баю, муллыкка ирешү
**Байморат** бай морат (теләк)
**Байрак** байрак, әләм, ялау
**Байраш – Бәйрәш** бәйрәм сыман рәхәт тормышта яшәүче

**Байсал** бай, байлыгы булган
**Байсар** сары (алтынлы) бай
**Байслан** бай арыслан
**Байсөек** бай сөек (сөекле бай)
**Байсөяр** бай сөяр
**Байтазар** бай тазар (нык, таза бул)
**Байтимер** бай тимер
**Байтирәк** зур һәм нык тирәк (борынгы бабаларыбызда *тирәк, байтирәк* изге агач (ыруг агачы) булып саналган. Бу исем ата йортында калачак ир балага кушыла)
**Байтуган** бай туган (килгән)
**Байтүләк** бай түләк (түләү акчасы)
**Байтүрә** бай түрә
**Байчура** бай чура (хәрби кеше)
**Байшат** бай шат, шат бай
**Байшункар** бай шункар (бөркет)
**Байытмыш** бай итүче бала
**Бакташ** таш кебек нык бала туды
**Бакты** бакты, карады, ягъни туды
**Бактыбай** бай туды
**Бактыбаш** баш (беренче ир бала) бакты, ягъни туды
**Бакырчы** ир баланың һөнәр иясе булуын теләп кушыла
**Бал** бал
**Балабан** яшь бөркет, ауга өйрәтелгән лачын[1]
**Балабаш** баш бала (беренче булып туган ир балага бирелә торган исем)
**Балаш** *бала* сүзенә *–аш (-ш)* иркәләү кушымчасы ялганган. *Балакай* мәгънәсендә
**Балбәк** *татлы бала* мәгънәсендә (*рус.* Балбек)
**Балкай** бал кебек татлы бала
**Баллыбай** бал кебек татлы бай

---

[1] Лачын – *рус.* сокол

**Балта** балта кебек нык, үткен булсын дип бирелә
**Балтабай** балта сыман нык һәм үткен бай
**Балтай** *балта* сүзенә *–ай* чакыру-эндәшү-боеру кушымчасы ялганган
**Балтан** *балта* һәм *–ан (-н)* иркәләү-эндәшү кушымчасы
**Балтач** балтачы, балта остасы
**Барак**[1] озын йонлы, затлы ау эте. Ир бала барак сыман сизгер һәм затлы булсын дигән теләк белән кушыла
**Барлас** батыр, кыю
**Барыс** барс, юлбарыс. Элек барыс елында туган ир балага *Барыс*[2] исемен бирү йоласы булган
**Барысбай** барыс елында туган бай
**Барысби** барыс елында туган би (князь)
**Барысбуга** юлбарыс һәм буга (үгез) сыйфатларына ия булган ир
**Барысбәк** барыс кебек бәк (башлык)
**Барысхан** барс сыман көчле һәм кыю хан
**Барыш** 1. килешү, ярашу; 2. солых, тынычлык
**Батман** батман – авырлык үлчәве
**Бату – Батый** 1. нык, таза; 2. ышанычлы
**Батыр** батыр, каһарман
**Батырай** батыр, кыю бул
**Батырбай** батыр бай
**Батырбулат** батыр булат

---

[1] Мәхмүд Кашгари үзенең “Диване лөгатет төрк” сүзлегендә болай дип аңлата: “Төркләрнең ышануларына күрә, картаеп килүче бөркет ике йомырка салып, аларны басып чыгара имеш. Йомыркаларның береннән шушы “Барак” атлы кечек пәйда була имеш. Этләрнең иң тиз йегергәне вә ауда иң ышанычлысы шул Барак этедер. Икенче йомаркадан исә бер чеби чыгар имеш. Бу аның балаларының ахыргысы булыр имеш”
(Kaşgarlı Mahmud. Divanü Lugati't-Türk. – Kabalcı Yayınevi, İstanbul, 2005. – 171 s.)

[2] Болгарларда һәм русларда киң таралган *Борис* исеменең дә *Барыс, Барис* сүзеннән килеп чыгуы мөмкин

**Батырбәк** батыр, баһадир бәк
**Батыргәрәй** батыр гәрәй
**Батыркай** *Батыр* исеменә *–кай* иркәләү кушымчасы ялганган
**Батырша** батыр шаһ (башлык, патша)
**Батырҗан** батыр, курку белмәс җан
**Батыш** батыр иш (батыр атага иш)
**Башбакты** өлкән ир бала бакты (туды)
**Башбүре** баш бүре
**Баян** бай, бәхетле, көчле
**Бәбек** бәбек, бәби, нәни бала
**Бәйрәм** бәйрәм көнне туган ир балага бирелә торган исем
**Бәйрәмбай** бәйрәм көнне туган бай
**Бәйрәмхан** бәйрәм көнне туган хан
**Бәк** би, князь
**Бәкбулсын** бәк (князь) булсын
**Бәктархан** аерым өстенлекләргә ия булган бәк (*рус.* Бектархан)
**Белек** белем, зирәклек, фән (*рус.* Билик)
**Белекле** 1. галим, укымышлы; 2. гакыллы, зирәк
**Белем** белем, гыйлем
**Белембай** белемле бай
**Белемчәк** *белем* сүзенә *–чәк* кечерәйтү кушымчасы ялганган
**Бәк – Би – Бик** 1. башлык, җитәкче, князь; 2. эре хуҗа, җир-су, байлык иясе. *Русча синонимы:* аристократ
**Биарслан** би арыслан
**Бибарс** би барс
**Бибек** бибек (күз бәбәге)
**Бибирде** би бирде, ягъни Тәңре би бирде
**Бибуга** *би, бәк* һәм *буга, үгез* сүзләреннән (ир баланың көчле һәм бай булуын теләп кушыла)
**Бигелди** би килде (туды)
**Биги** батыр, герой
**Бигиш – Бигеш** бик ише (баласы), бәк улы

**Бигәш – Бигәч** хан улы, *рус*. “принц”
**Бидоган – Битуган** би, бәк туган, дөньяга килгән
**Бииш** би ише, князь, түрә улы
**Бикбай** бик бай
**Бикбатыр** көчле батыр, каһарман
**Бикбау** нык бау (*йола исеме*: бу бала нәсел җеп-бавын дәвам итсен дигән теләк белән бирелә)
**Бикбирде** бик бирде, ягъни Күк Тәңре би, бәк булачак бала бирде
**Бикбул** 1. көчле, нык бул; 2. бәк бул
**Бикбулат** каты булат (корыч)
**Бикбулды** бик (бәк) булды (туды)
**Биккенә** бик (бәк) кенә булсын
**Биккәй** *бик* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган
**Бикләмеш** күтеп алынган, көттереп килгән бала (*бәкләмәк, бикләмәк* – көтү, көтеп тору)
**Бикморза** бик (бәк) морза
**Бикмән** бик (бәк) мән (мин)
**Биктархан** бик (бәк) тархан
**Бикташ** таштай нык бәк (ир бала нык һәм хаким булсын дип кушыла)
**Биктимер** тимер бәк (ир бала тимер кебек нык түрә булсын дип теләп бирелгән исем)
**Биктирәк** нык, таза бәк
**Биктуган** бәк туган
**Биктутук** нык тотучы бәк
**Биктәш** бәк ише
**Бикхан** бик (бәк) хан
**Бикчура – Бикчурай** бик (бәк) чурасы (баласы, токымы)
**Бикчәнтәй** төпчек бик (бәк), иң кече ир бала
**Бикшад** борынгы төркиләрдән килгән ике югары титул кушылып ясалган: *бик* һәм *шад*

**Билбирде** ир бала, ягъни бил, таяныч бирде
**Билгелди** бил, таяныч килде
**Бирдебай** бай булачак бала бирде
**Бирдебәк** бәк булырдай бала бирде
**Бирдеиш** иш, тиң бирде
**Бирдехан** хан булырдай бала бирде
**Бирдеяр** яр, дус, терәк бирде
**Бирсенбай** бай булачак бала бирсен
**Буртас** борынгы бабаларыбыздан булган төрки кабилә
**Бирчебай** бай булыр ир бала бирче мәгънәсендә
**Битаман** борынгы төркиләрдән килгән югары титул һәм исем кушылып ясалган: *би* һәм *Таман*
**Битуган** би (бәк) туган
**Бичура** би (князь) чурасы, баласы
**Бишбүләк** биш бүләк, ягъни ата кешегә иң олы бүләк – ир бала
**Бога – Буга** үгез (бала көчле булсын дигән теләк белән кушыла)
**Болан** горур һәм җитез мәгънәсендә
**Боланбай** болан бай
**Боланкай** *болан* сүзенә *–кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы кушылган
**Боланчы** боланчы
**Болгар** борынгы шәһри Болгар исеме
**Борнак**[1] борыны ак

[1] Гомәр Саттар-Мулилле “Татар исемнәре ни сөйли?” дигән китабыда болай дип аңлата: “Теге яки бу аксакалның кызы гына булып, улы булмаса, шул кыздан туган беренче ир баланы, ак борынлы ат янына салып, аңа Борнак дигән ат исемен (зоонимны) исем итеп кушканнар. Бу йола юрматы кабиләсе башкортларында озак яшәгән. Бурнаков, Бурмаков фамилияләрендә сакланган. Русларда да шушы исемнән ясалган Бурнак, Бурнаков фамилияләре бар” (Гомәр Саттар-Мулилле. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: “Раннур” нәшрияты, 1998. – 65 бит)

**Борнаш** борнаш – борынлау, шытып, тишелеп чыгу
**Борындык** тырыш җәнлек
**Бөкәй** батыр, герой
**Бөкәйхан** батыр, каһарман хан
**Бөркет** ир бала бөркет кебек булсын дигән теләктән чыгып кушыла
**Бөркетбай** бөркет кебек кыю, батыр бай
**Бөрҗан – Борҗан** бөре (бүре) җан
**Бугаарслан – Бугуруслан** буга (үгез) кебек арыслан
**Бузан** бузан, ягъни буйга җит, озак яшә
**Булат** иң сыйфатлы корыч (ир бала яхшы корыч кебек нык булсын дип бирелә)
**Булатбай** бай булат
**Булаттимер** тимер булат
**Булатхан** көчле, дошманнарын җиңүче хан
**Булгак – Болгак** болганучан, ягъни җанлы, тиктормаучан, тырыш
**Булган** булган, уңган
**Булдыиш – Булдыш** иш булды
**Булыш** булышучы, ярдәм итүче ир бала туды
**Буран** буранлы көндә туган балага бу исем бирелсә, ул һичшиксез бәхетле була имеш
**Буранбай** буранлы көндә туган бай
**Буранчы** буранлы көнне туучы
**Бурсык** бик чиста, тырыш җәнлек
**Бүзәк** *бүз* (ак) сүзенә *-әк* иркәләү кушымчасы кушылып ясалган исем
**Бүзәргән** бүз (ак) әргән (буй җиткән, җитлеккән). Бу исем бала тиз үссен дигән теләктән чыгып кушыла
**Бүзтанай** *бүз* һәм *таң* сүзләреннән килеп чыккан исем
**Бүзтимер** аксыл төстәге тимер
**Бүзтирәк** бүз (ак) тирәк
**Бүзтуган – Бузтуган** бүз, чал булып озак яшәр өчен туган

**Бүзъегет** буй җиткән егет

**Бүләк** йола исем. Атасы яки анасы үлгән сабыйларга бирелә. Йоланы бозган очракта бала чирле була, диләр

**Бүләкбай** үлгән атасыннан (анасыннан) бүләк булып калган бай

**Бүләкбирде** бүләк бирде

**Бүлтерек** бүре баласы

**Бүре** ир бала бүре сыман көчле, явызлар һәм дошманнар өчен дәһшәтле булсын, дип кушылган исем (*рус*. Буре)

**Бүребай** бай бүре

**Бүрекәй** *бүре* сүзенә *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган

**Бүриш** бүре ише, баласы

**Бүрехан** *бүре* һәм *хан* сүзләреннән ясалган, дастаннарда сакланып килгән исем

# Г

**Гәрәй** көчле, кодрәтле

**Гәрәйбәк** көчле, кодрәтле бәк

**Гәрәйхан** көчле, кодрәтле хан

**Гүзәлбай** матур, гүзәл бай (ир бала)

**Гүзәлхан** матур, гүзәл хан (ир бала)

# Д

**Даиш – Таиш** *дай (тай)* һәм *иш* сүзләреннән ясалган. Тай кебек юлдаш, иптәш ир бала

**Дамир** “Да здравствует мир!” лозунгысыннан кыскарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Көньяк төркиләргә хас булган *дәмир (тимер)* сүзеннән килеп чыгуы да мөмкин

**Данат** данлы ат, исем. Дан казанган кеше

**Дарьял** капка, үткел

**Дәвеш** – **Дәвиш** *дәв (дәү)* һәм *иш* сүзләреннән ясалган. Баш (беренче) балага кушыла
**Дәүбай** бик, гаҗәп бай
**Дәүбәк** олы, өлкән бәк
**Дәүлекам** ил, дәүләт камы (дин башлыгы)
**Дәүлихан** *дәүләт* һәм *хан* сүзләреннән
**Дәүхан** бөек, гаҗәп олы хан
**Дәүҗан** гаҗәп, олы җан
**Дәһли** Һиндстан башкаласы
**Дөрестуган** дөрес, тугры туган
**Дилиш** ике мәгънәгә ия: 1. сөекле иш; 2. кыю, батыр иш
**Дилүс** күңел үс (үсә)
**Диңгез** диңгез кадәр киң күңелле һәм диңгездәй зур белемле ир бала
**Диңгезбай** диңгез бай
**Диңгезхан** диңгез хан
**Дулат** төрки кабилә исеме
**Дулкын** ир баланың хәрәкәтчән булуын теләп кушыла
**Дунай** елга, зур су
**Дусай** *дус* сүзенә *–ай* кушымчасы ялганып ясалган
**Дусак** *дус* сүзенә *–ак* кушымчасы ялганып ясалган
**Дусакбәк** дусак бәк
**Дусби** дус би (бәк)
**Дусбиргән** дус (бала) биргән
**Дусым** дустым, якыным

# Е

**Егет – Җегет** булдыклы, җитез (*рус*. Джигит)
**Егетбай** егет, булдыклы бай
**Едегәр** – **Едигир** – **Едигер** изге, игелекле ир
**Елгыр** елгыр, җитез, уңган
**Елдам** елдам, җитез, өлгер

**Елкыбай** елкы (ат) елында туган ир балага кушыла

**Елкычура** елкы елында туган батыр

**Еникәй** – **Еники** *йөни* (яңа) сүзенә *–кәй* кушымчасы ялганып ясалган

**Ерикәй** – **Ерики** *ер* (ир) сүзенә *–кәй* кушымчасы ялганып ясалган

# З

**Зәй** төрки телләрдә *зай – зәй – сай – сәй – чай* сүзе елга төшенчәсен белдерә. Мәсәлән, Йенисәй (*рус.* Енисей)

# Җ

**Җәүген** күктән җауган (яуган), иңгән, төшкән. Илаһи зат мәгънәсендә (*рус.* Джевген[1])

**Җидегән** җидегән йолдыз[2]

**Җилдәр** җилдәй, җитез

# И

**Иббирде** тиң (бала) бирде мәгънәсендә

**Игез** игез, икеләч, икәү, пар

**Игебулат – Игибулат** изге, яхшы булат (*иге, иги, ийе, ие* ягъни изге, яхшы сүзенә *булат* сүзе кушылып ясалган)

**Игедәүләт** – **Игидәүләт** дәүләт иясе, киң күңелле бай (*иге, ийе, ие, иги* ягъни изге, яхшы сүзенә *дәүләт* сүзе кушылып ясалган)

**Игезбай** кыз бала белән игезәк булып туган бай (ир бала исеме)

**Игезбәк** игезәк туган бәк (ир бала). Кыз бала белән игезәк булып туган ир балага кушыла (*рус.* Игезбек)

---

[1] Руслар борынгы бу төрки исемне *Евгений* рәвешендә кулланалар

[2] Олы Җидегән – Большая Медведица, Кече Җидегән – Малая Медведица

**Игенбай** игенгә, икмәккә бай

**Идеал**[1] изге, илаһи ут, ялкын. Борынгы төрки-татар *иди, изи* (илаһи, гөнаһсыз, пакъ) сүзенә *ал,* ягъни ут сүзе кушып ясалган

**Идебәк** изге бәк. Борынгы төрки-татар *иди, изи* сүзенә *бәк* сүзе кушылган

**Идегәй – Идекәй** *иде, иди* сүзенә *–кәй* кушымчасы ялганып ясалган

**Идел** изге, илаһи. *Иде, иди* сүзеннән. Елга исеме буларак билгеле

**Иделбай** идел бай

**Иделбакты** туу белән Идел ягына борылып караган ир балага кушылган исем

**Иделбәк** Идел буенда яшәүче бәк (би, князь)

**Иделсабый** елга буендагы җәйләүләрдә туган ир балага бирелгән исем

**Иделхан** Идел буе ханы

**Иделхуҗа** идел хуҗа

**Изибай** байлыгы *изидән* (алладан) килгән бай

**Изил** илаһи, *рус.* божественный. *Изи* сүзеннән. Мәхмүт Кашгарыйда башка мәгънәсе дә бар: азат ителгән, ирекле

**Икбакты** "орчык" мәгънәсен белдергән *ик (иг)* сүзеннән. Бу исем бик кечкенә булып туган ир балага кушыла

**Ил** 1.ил, дәүләт, ватан, йорт-җир, өлкә; 2. солых, тынычлык. Шумер телендә *el* – якты, чиста җир. *Исем компоненты*

**Иләман** ил имин, тыныч мәгънәсендә

**Иләмбай** иләмле, чибәр бай

**Илбай** ил бае, ил агасы

**Илбакты** илен багучы, караучы, аны кайгыртучы

---

[1] Иде, иди, изи – борынгы төрки-татар сүзе. Берничә мәгънәсе бар: 1. алла, илаһ, тәңре; 2. илаһи, гөнаһсыз, изге, пакъ; 3. көчле, кодрәтле зат, падишаһ. Изи сүзе инглиз телендә дә *(easy)* шуңа охшаш мәгънәгә ия – җиңел, тыныч. Гөнаһ авырдыр, ә менә изгелек җиңелдер

**Илбарс** ил батыры
**Илбәк – Илбик** ил бәге, ил хуҗасы
**Илбатыр** ил батыры
**Илбизәр** илен бизәүче
**Илбул** ил агасы бул мәгънәсендә
**Илгиз – Илгизәр** ил гизүче
**Илгәзәк** кешегә ягымлы
**Илдан** ил даны
**Илдар** 1. илле, ватанлы; 2. ил башлыгы
**Илдархан** *илдар* һәм *хан* сүзләреннән
**Илдуган – Илтуган** ил агасы туган
**Илдус** ил дусты, илен сөюче
**Илдәнур** илдә нур
**Илзат** ил заты
**Илиш** ил ише (әш, иш – тиңдәш)
**Илкилде** тынычлык килде мәгънәсендә. Сугыш беткәч туган ир балага бирелгән
**Илкен** беренче бала, тәүге угыл
**Илкәй** *ил* сүзенә *–кәй* иркәләү кушымчасы ялганып ясалган
**Илкәч** *ил* сүзенә *–кәч* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган
**Иллебай** илле яшенә җиткән ир-аттан туган бала
**Илморза** ил агасы, ил хуҗасы
**Илназ** *ил* һәм *наз* сүзләреннән
**Илнур** ил нуры
**Илсөяр** үз илен яратучы
**Илтабар** *ил* һәм *табар* сүзләреннән
**Илтазар** илен тазартучы, ныгытучы, яңартучы
**Илтаң** ил таңы
**Илтимер** илнең тимер кебек нык кешесе
**Илтирәк** илнең таянычы
**Илтоткан** илне тотучы, ил хуҗасы
**Илүс** ил үсә

**Илхан** ил башлыгы титулы
**Илче** ил вәкиле
**Илчебай** илче бай
**Илчебәк** илче бәк
**Илчекәй** *илче* сүзенә *–кәй* иркәләү кушымчасы ялганып ясалган
**Илчура** илнең чурасы, батыр сугышчысы
**Имән** бу исем баланың имәндәй нык булуын теләп кушыла (*рус.* Имян)
**Имәнбай** имән кебек нык бай
**Имәнкилде** имән кебек таза бала туды
**Имәнкискә** имән кискәседәй нык, таза
**Имкилде** им килде
**Имче** дәвалаучы, савыктыручы, шифа бирүче
**Инал** хан улы, аксөяк
**Ирбай** *ир* һәм *бай* сүзләреннән
**Ирбәк** *ир* һәм *бәк (князь)* сүзләреннән
**Ирби** *ир* һәм *би (князь)* сүзләреннән
**Ирек** азатлык, хөрлек
**Иркә** иркә, кадерле
**Иркәбай** иркә бай
**Иркәш** *ир* сүзенә *–кәш* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган
**Иркен** 1. азат, хөр; 2. мул тормышлы, киң дәүләтле
**Иркенбай** *иркен* һәм *бай* сүзләреннән
**Иркенбәк** мул тормышлы бәк (князь)
**Иркот** кот-бәхет китергән ир бала, бәхетле егет (*рус.* Иркут)
**Иржемәс** авырмас, сыкранмас
**Исәкәй** кызык, юаныч (*рус.* Исякай)
**Исән** сау-сәламәт (*рус.* Исен)
**Исәнаман** *исән* һәм *аман* сүзләреннән (*рус.* Исенаман)
**Исәнгилде – Исәнкилде** сау-сәламәт килде, туды
**Исәнтимер** ир балага тимердәй нык булуын теләп кушыла

**Исәнтор** исән тор, яшә (*рус.* Исентур)

**Исәнчек** исән сүзенә –чек иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган

**Исәнчура** сау-сәламәт сугышчы

**Исәньяр** сау-сәламәт дус, иптәш

**Ишбай**[1] *иш* һәм *бай* сүзләреннән

**Ишбак** гаиләне ишәйтүче дөньяга бак, ягъни ту

**Ишбакты** булышчы, иптәш, охшаш, тиң, ярдәмче яисә гаиләне ишәйтүче бала бакты, туды

**Ишбар** *иш* һәм *бар* сүзләреннән. Күп мәгънәле борынгыдан килгән исем

**Ишбарс** *иш* һәм *барс* сүзләреннән

**Ишбатыр** *иш* һәм *батыр* сүзләреннән

**Ишбирде** *иш* һәм *бирде* сүзләреннән

**Ишбул** *иш* һәм *бул* сүзләреннән

**Ишбулат** *иш* һәм *булат* сүзләреннән

**Ишбулды** *иш* һәм *булды* сүзләреннән

**Ишбүләк** *иш* һәм *бүләк* сүзләреннән. Йола исеме: әтисе үлгәч туган ир балага бирелә. Атасы бүләге

**Ишем – Ишим** минем ишем мәгънәсендә

**Ишембай** *ишем* һәм *бай* сүзләреннән

**Ишемкәй** *ишем* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган

**Ишемъяр** минем ишем, дустым, ярым

**Ишҗегет – Ишъегет** *иш* һәм *егет* сүзләреннән (*рус.* Ишджигит)

**Ишкап** *иш* һәм *кап* (кан кардәш, якын туган) сүзләреннән ясалган исем

**Ишкара** иш кара, ягъни ту, дөньяга кил

---

[1] Иш – күп мәгънәле борынгы сүз: 1. пар, тиң булырлык кеше, үзе кебек кеше. Мәсәлән, *үз ишеңә өйләнү*; 2. нәрсәгә дә булса охшаш, шул ук сыйфатка ия. Мәсәлән, *моңа иш гүзәллек юк*; 3. булышчы, дус, иптәш, юлдаш, ярдәмче; 4. ир яисә хатын. Рус. супруг(а); 5. җөп, так түгел

**Ишкенә** *иш* һәм *кенә* сүзләреннән
**Ишкил** иш кил (ту)
**Ишкилде** иш килде (туды)
**Ишкуәт** нәселнең куәтен арттыручы
**Ишкәй** *иш* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган
**Ишлебай** ишле бай
**Ишлияр** ишле дус, яр
**Ишман** иш кеше
**Ишнарат** ир балага нарат агачы кебек нык һәм зифа булуын теләп кушыла
**Ишсары** *иш* һәм *сары* (алтын, байлык) сүзләреннән. Кадерле бала
**Иштай** *иш* һәм *тай* (үсмер ат) сүзләреннән
**Иштаң** таң ише
**Иштимер** *иш* һәм *тимер* сүзләреннән
**Иштирәк** *иш* һәм *тирәк* (таяныч) сүзләреннән. Йола исеме: игезәк ир баланың берсенә *Иштирәк*, икенчесенә *Куштирәк* исеме бирелә
**Иштуган** *иш* һәм *туган* сүзләреннән
**Иштукай** *иш* һәм *тукай* сүзләреннән
**Иштүрә** *иш* һәм *түрә* сүзләреннән
**Ишхан** *иш* һәм *хан* сүзләреннән
**Ишчура** *иш* һәм *чур*а (бала, игенче, сугышчы) сүзләреннән
**Ишъяр** *иш* һәм *яр* сүзләреннән
**Ишәй** арт, күбәй мәгънәсендә

# Й

**Йаган** фил кебек
**Йобанай** куаныч, юаныч
**Йозак** баланың үлеме йозаклансын мәгънәсендә (*рус.* Юзак)
**Йолдыз** йолдыз кебек нурлы, якты
**Йомгалак** 1.йомгаклау, очын яшерү; 2. табышмак

# К

**Кабай** кабык бишек, бәллү

**Кабан** ир баланың кабан кебек көчле булуын теләп кушыла

**Кабанбәк** көчле бәк (князь)

**Каган** олы хан, ханнар ханы

**Каганбәк** каганның урынбасары, премьер-министр (*рус.* Каганбек)

**Казак** 1.атлы гаскәри; 2. ирекле кеше

**Казакбай** бай казак

**Казан** бала ризыклы булсын дип бирелгән исем (*рус.* Казан)

**Казанай** *казан* сүзенә *–ай* чакыру-эндәшү кушымчасы ялганган

**Казанбай** *казан* һәм *бай* сүзләреннән. Мул ризыклы мәгънәсендә

**Казанбәк** *казан* һәм *бәк* сүзләреннән

**Казбәк** биек тау түбәсе

**Кай** 1.нык; 2. кабилә атамасы

**Кайхан** кай кабиләсе ханы

**Кайчура** кай кабиләсе чурасы (баласы, сугышчысы)

**Калмыш** исән калмыш мәгънәсендә

**Камбулат** кам (дин әһеле) һәм булат сүзләреннән

**Канак** татлы бала

**Канат** ата-анага тормышларында терәк

**Каплан** барс, леопард

**Карабай**[1] көчле, куәтле бай

**Караби** көчле, куәтле би (князь)

**Карабуга** атаклы батыр, каһарман

**Карабәк** көчле, куәтле бәк (князь)

**Карагай** баланың карагай агачы сыман нык булуын теләп кушыла

---

[1] Кара сүзе 1. дәһшәтле, көчле, куәтле; 2. бай, күп, мул; 3. җир, туфрак; 4. кара төс; 5. бак, ту, дөньяга кил дигән мәгънәләрне белдерә

**Караган** караган, туган, дөньяга килгән

**Карагач** баланың карагач шикелле нык булуын теләп кушыла

**Караиш** куәтле иш

**Карай** дәһшәтле, куәтле, көчле

**Каракай** *кара* сүзенә *–кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган

**Каракаш** кара кашлы ир балага кушыла

**Каракилде** көчле, куәтле бала килде (туды)

**Каракош** баланың каракош (бөркет) кебек батыр булуын теләп кушыла

**Каракөчек** әгәр гаиләдә балалар үлгән булса, бу исем бирелә (көчек сыман яшәүчән булсын, дигән теләк белән)

**Каракүз** кара күзле бала. Бай, көчле, куәтле (*рус.* Карагюз)

**Караман** *кара* (бай, куәтле) һәм *ман, мән* (кеше) сүзләреннән

**Карамыш** карамыш, ягъни тумыш мәгънәсендә

**Каранай** җитди кыяфәтле кеше

**Каратай** *кара* һәм *тай* сүзләреннән

**Караташ** баланың изге таш сыман нык булуын теләп кушыла

**Каратимер** *кара* һәм *тимер* сүзләреннән. Изге тимер мәгънәсендә

**Каратуган** *кара* һәм *туган* сүзләреннән

**Карач** кара тутлы кеше

**Карачар** көчле, ишле гаиләле

**Карачман** кара тутлы кеше

**Карачура** батыр кеше, сугышчы

**Карачы** министр. Казан ханының дүрт карачысы булган (*рус.* Карачи)

**Кари** карт (белемле) кеше, аксакал

**Карлыхан** кар яуган көнне туган хан

**Карнай** боргы, мөгез

**Катау** коймалы торак урын, *рус.* крепость. Катауларда биләр, ханнар яшәгән

**Качмас** качмас, качып китмәс

**Кашкар** бүре. Явызлар өчен дәһшәтле булсын, дигән теләк белән кушыла

**Келәш** киләү аенда (октябрь) туган бала

**Кечебай** төпчек балага кушыла

**Киек** болан, кыргый җәнлек сыман җитез булсын, дип кушыла

**Киекбай** *киек* һәм *бай* сүзләреннән. Җитез бай

**Киекхан** *киек* һәм *хан* сүзләреннән. Җитез хан

**Килбай** бай туды мәгънәсендә

**Килбаш** баш бала туды мәгънәсендә

**Кобай** *коба* (төс) сүзенә *–ай* чакыру-эндәшү кушымчасы ялганган

**Кобан** 1. җитез, ургылып ага торган; 2. коба төстәге (*рус.* Кубань). Елга һәм төбәк исеме

**Кобач** коба төстәге

**Кондыз** кондыз (бобр) сыман тырыш булсын, дигән теләк белән кушыла

**Кортай** *корт* (бүре) сүзенә *–ай* атау-эндәшү кушымчасы ялганган

**Корыч** корыч сыман нык булсын, дигән теләк белән кушыла

**Котан** кот (бәхет) иясе, бәхетле

**Котлы** 1. бәхетле, данлы, мактаулы; 2. исән-имин, җанлы (*рус.* Кутлу)

**Котлыбай** котлы бай

**Котлыбарс** котлы барс

**Котлыби** котлы би (князь, бай, олигарх)

**Котлыбирде** тәңре котлы (бәхетле) бала бирде

**Котлыбуга** бәхетле һәм үгез кебек көчле

**Котлыбәк** котлы бәк (князь, бай, олигарх). *Рус.* Кутлубек

**Котлык** бәхет иясе, бәхетле (*рус.* Кутлук)

**Котлыкай** *котлы* сүзенә *–кай* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган

**Котлыкил** бәхетең белән кил, ту

**Котлыкилде** бәхетле бала килде, туды (*рус.* Кутлукелди)
**Котлыхан** котлы хан
**Котлычура** котлы чура
**Котлыюл** гомер юлы бәхетле булган бала (*рус.* Кутлуюл)
**Котлыяр** котлы яр (дус, иптәш). *Рус.* Кутлуяр
**Котсал** бәхетле (*рус.* Кутсал)
**Котый** бәхетле, бәхет иясе
**Котчы** бәхетле, бәхет иясе (*рус.* Кутчи)
**Котык** бәхет (*рус.* Кутук)
**Куандык** сөендек, шатландык
**Куар** яшен алласы
**Кунай** 1. горур; 2. кояш кебек (*күн*, *көн* – кояш димәк); 3. шатлык
**Кунак** көтеп алынган бала
**Курт – Корт** бүре кебек көчле булсын, дигән теләк белән кушыла. Бу исем немецларда һ.б. Европа халыкларында да очрый
**Кутлуг** бәхетле кеше
**Кучкар** куй (сарык) тәкәсе
**Күгәй** күк күзле бала (*рус.* Кугей)
**Күгәрчен** кош исеме, ир балага кушыла
**Күзбай** күз кебек кадерле ир бала
**Күзби** күз кебек кадерле би (бай, князь)
**Күзбәк** күз кебек кадерле бәк (бай, князь)
**Кылавыз** юл күрсәтүче (*рус.* Кулавуз)
**Кылыч** явызлар баладан кылычтан шүрләгән сыман курыксыннар, дигән теләк белән кушыла
**Кыпчак** күп санлы, көчле төрки халык. Татар-мишәрләрнең бабалары. Балага ишле гаиләле булуын теләп кушыла
**Кырлай** *кырлай*, ягъни *кырлач ай*. Кышның иң салкын вакытында туган балага кушыла
**Кырлач** кышның иң салкын ае – *кырлач* аенда туган бала
**Кырым** 1. *кыр, җир* сүзеннән. Кырым, ягъни (минем) җирем; 2. ныгытма, өлешләргә аеручы кыр, өем (*рус.* Крым)

**Кырымсарай** *кырым* һәм *сарай* (дворец) сүзләреннән. Бала үз җирендә сарай хуҗасы, ягъни ил башлыгы булсын, дигән теләк белән кушыла

**Кырымхан** кырым ханы, ягъни үз җиренә хуҗа булган хан

# Л

**Лачын** лачын кошы кебек кыю, батыр

# М

**Мамай** бәкләрбәк (бәкләр бәге), татар морзасы. *Мәми, мәмә* (ризык) сүзенең элекке варианты булган "мама"дан килеп чыккан, дип фараз итәргә була

**Мангут** төрки кабилә атамасы

**Мәнгүш** мәңге иш (озак яшәр бала). *Рус.* Мангуш

**Мир** (*р* йомшак) галәм, дөнья; җәмгыять, кешелек дөньясы, халык

**Миңлебай** бәхетле бай

**Миңлеиш** бәхетле иш (дус, бала)

**Миңлекәй** *миңле* (бәхетле) сүзенә *-кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган

**Миңлеяр** бәхетле яр (дус, иптәш)

**Мортак** атлы, аты булган, җайдак. Тәләйле, тормышы җиңел барган мәгнәсендә

# Н

**Нарат** мәңге яшел агач сыман картаймас мәгънәсендә

**Нократ** 1. эретелгән саф көмеш; 2. елга атамасы

**Нугай** төрки ыруг һәм халык исеме

**Нугайбәк** нугай бәге

# О

**Олан** 1. углан, угыл; 2. атлы сугышчы (*рус.* Улан)
**Олыхан** олы хан
**Очкын** чаткы

# Р

**Рысбай** бәхетле бай (*рыс, ырыс* – бәхет)
**Рысбуга** бәхетле һәм буга (үгез) кебек көчле (*рус.* Русбуга)

# С

**Сагынбай** сагынып, көтеп алынган бай (ир бала)
**Сәйдәш** кардәш. Сәй (сой) – нәсел, ыруг
**Сукман** батыр

# Т

**Тархан** биләргә бирелгән дәрәҗәле исем. Тархан салымнар түләүдән азат ителгән
**Теләй** бәхет, уңыш
**Теләк** теләп алынган бала
**Теләш** көтеп, теләп алынган бала
**Тени** бала, угыл, ул
**Тенибәк** бала бәк, атасы янында кече бәк (*рус.* Тенибек)
**Тениш** борынгы төрки телдәге *тени (тенәй)*, ягъни бала сүзенә *–ш* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы яисә *иш* сүзе ялганып ясалган. Рус князьләре Тенишевлар мәгълүм
**Тенәкәй** *тени*, ягъни бала сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганган. Тенеки – Татарстан Республикасының Саба районындагы авыл атамасы
**Тимер** бала тимердәй нык булсын, дигән теләк белән кушыла
**Тулай** тулы айда туган бала

**Тулпар** канатлы ат
**Тумак** никахсыз хатыннан туган балага кушыла
**Туматай** нәселдәш, бертуган ир бала
**Тупач** туп кебек тулы, түгәрәк бала
**Тургай** тургай сыман булсын дигән теләк белән кушыла
**Түрә** закон, кагыйдәләр җыелмасы (*рус.* Торе)
**Түрк** төрки 1. туганнар, кардәшләр союзы; 2. берлек, кодрәт, көч (*рус.* Тюрк)

# Ү

**Үктәй** ыруг, нәсел-нәсәп кешесе, туган кеше (*рус.* Уктай)
**Үтәгән** *үтәү* сүзеннән килеп чыккан – теләкне үтәгән. Гаиләдә озак балалар булмагач, Тәңредән бала сорап йолалар башкарганнан соң туган затка кушыла (*рус.* Утяган)
**Үтәй** Тәңредән сорап алынган бала (*рус.* Утей)
**Үтәк** теләк үтәлеп туган бала (*рус.* Утяк)
**Үтәмеш** Тәңре теләкне үтәмеш мәгънәсендә (*рус.* Утямеш)
**Үтәш** үтәш – үтәлеш. Тәңредән сораганнан соң дөньяга килүче (*рус.* Утяш)

# Ч

**Чабак** чабак балыгы кебек җитез
**Чага** яраткан бала
**Чагатай** 1. батыр, кыю; 2. ихлас күңелле, намуслы
**Чакмак** ут чыгаручы, өләшүче. *Синонимы*: Прометей
**Чалбай** баланың чал (таш) кебек нык, таза һәм бай булуын теләп кушыла
**Чалбулат** таш булат
**Чалтугай** ташлы тугай
**Чалым** охшашлык. Әтисенә охшаган балага кушыла
**Чанбай** бүредәй куркусыз һәм йөрәкле бай

**Чанчура** 1. бүре углы; 2. батыр сугышчы
**Чаныш** бүре имше. Баланың бүрегә тиң булуын теләп кушыла
**Чапай** *чап* (дан) сүзенә *–ай* чакыру-эндәшү кушымчасы ялганган. Борынгы төрки исем
**Челебәй – Челеби – Чиләбе** 1. матур, сөйкемле; 2. белемле бай, бәй, би, бәк, князь. *Рус.* Челебей – Челяби
**Чирүбай** чирү (гаскәр) башлыгы
**Чуак** аяз, якты көн. Баланың гомере аяз, болытсыз, якты булсын, дип кушыла
**Чук** шул исемле бәйрәм көнне туган балага кушыла
**Чуклы** ишле, мул, күп
**Чукхан** Чук бәйрәме көнне туган хан
**Чура** 1. батыр сугышчы; 2. дус, иш; 3. игенче, хезмәтче
**Чыңгыз** бөек, кодрәтле, көчле. *Рус.* Чингиз

# Ю

**Юаныч** ата-ана юанычы булган бала
**Юлай** юл күрсәткеч, факел
**Юлбакты** юлда туган балага бу исем бирелә
**Юлбарыс** баланың юлбарыс кебек көчле булуын теләп кушыла
**Юлбуга** *юл* һәм *буга* (үгез) сүзләреннән. Балага озын гомерле һәм көчле булсын дигән теләк белән кушыла
**Юлгиз** гомер юлы озын булган, озак яшәүче
**Юлдаш** ата-анага иптәш
**Юлдашбай** бай юлдаш
**Юлкотлы** бәхетле гомер теләп кушыла
**Юллы** озын гомерле
**Юллыбай** озын гомерле бай
**Юллыхан** озын гомерле хан
**Юлтай** озын гомерле тай (бала)
**Юлтаң** таң кебек якты гомерле

**Юлтимер** гомере буе тимердәй нык булсын, дигән теләк белән кушыла

**Юлчура** озын гомерле батыр

**Юньбәк** әдәпле, тәртипле бәк (князь)

# Я

**Ябалак** ябалак – бәхет китерүче кош. Баланың бәхетле булуын теләп кушыла

**Ябгу** баш кеше, башлык, хан

**Ялав** байрак, байрак сабындагы чук

**Япанча – Япанчы** далада туган балага кушыла. Япанча – бурка, җиңсез киң плащ

**Яркай** дускай

**Ярук** таң йолдызы. *Синонимы*: Чулпан

**Яссы** тигез, ялпак. Гомер юлы сикәлтәсез, тигез, төз, туры, шома булсын, дип кушылган исем

**Яшәр** озын гомерле булыр дигән мәгънәдә

## *Бәхет китерүче хатын-кыз исемнәреннән үрнәкләр*

# А

**Абызбикә** *абыз* (дәрәҗәле, тәҗрибәле) һәм *бикә* (бай, бәк, би хатыны; аксөяк хатын-кыз) сүзләреннән

**Азалия** азалия гөле

**Азия – Асия** дөнья кисәге, материк

**Айбикә** ай сыман бикә

**Айбикәч** ай кебек бикәч (1. ярәшелгән, димләнгән кыз, кәләш; 2. яңа гына кияүгә чыккан яшь хатын)

**Айбүләк** ай кебек нурлы, якты бүләк (кыз)

**Айва** татлы җимеш

**Айгизә** айга менә (*рус.* Айгизя)
**Айгына** айга тиң
**Айгөл** ай гөле
**Айгөлем** ай гөлем
**Айзифа** ай кебек сылу, чибәр
**Айкаш** яңа ай сыман кыйгач кашлы
**Айлы** ай кебек сылу, чибәр
**Айлыбикә** ай кебек нурлы, чибәр бикә
**Айназ** ай кебек назлы
**Айсолтан** *ай* һәм *солтан* сүзләреннән
**Айсылу** ай сылуы, чибәре
**Айсың** айга тиңсең (*рус.* Айсын)
**Айсөяр** ай сөяр, матурлыкны яратыр (*рус*. Айсияр)
**Айчибәр** ай кебек матур (*рус.* Айчибяр)
**Айчирә** йөзе ай кебек, ай йөзле
**Айчәчәк** ай сыман матур чәчәк (*рус.* Айчечек)
**Акбашак** ак тәнле кыз
**Акбикә**[1] ак бикә
**Акбүләк** *ак* һәм *бүләк* сүзләреннән
**Акҗан** ак, чиста күңелле кеше (*рус.* Акджан)
**Аккош** аккош кебек чибәр
**Аккыз** чибәр кыз мәгънәсендә
**Аксыл** аксыл төс-битле
**Акчәчәк** саф, намуслы, чәчәк кебек кыз
**Албикә** 1. ал йөзле бикә; 2. алгы, тәүге бикә. Гаиләдә беренче булып туган кыз балага бирелә
**Алгөл** ал гөл, чәчәк
**Алкын** булган, уңган, тиз
**Алма** алма кебек чибәр
**Алсу** алсу йөзле, матур, чибәр

---

[1] Ак сүзе күп мәгънәле: 1. кар, сөт төсе; 2. якты, нурлы; 3. чиста, керсез, пакъ; 4. гөнаһсыз, саф, эчкерсез; 5. ягымлы, җылы; 6. гадел, тугры, ышанычлы; 7. бәхетле, рәхәт, кайгы-хәсрәтсез

**Алсылу** ал йөзле сылу
**Алтаң** ал таң кебек сылу йөзле
**Алтынбикә** алтын кебек кадерле бикә
**Алтынгөл** алтын кебек кадерле гөл (кыз)
**Алтынчәч** алтын төсле сары чәчле (*рус.* Алтынчеч)
**Алчирә** ал йөзле, чибәр (*рус.* Алчира)
**Алчәчәк** ал чәчәк (*рус.* Алчечек)
**Анапа – Анапай** ана пае, өлеше. Анасына бик охшаган кызга кушыла
**Аппак** бик саф, керсез, пакъ
**Артыкбикә** йола исеме. Әгәр гаиләдә гел кыз балалар гына булса, җитәр инде, дигән мәгънәдә бу исем кушыла
**Арубикә** ару (пакъ, саф, чиста) бикә
**Асена** ана бүре, батыр кыз
**Ары** саф, берни дә катнашмаган, чип-чиста, пакъ (*рус.* Ари)
**Ахак** агат, асылташ

# Б

**Байбикә** бай бикә
**Байсылу** бай сылу
**Байсөяр** бай сөяр (*рус.* Байсияр)
**Балбикә** бал кебек татлы бикә
**Балкыш** балкып торучы, нур чәчүче
**Балсылу** бал сыман татлы сылукай
**Бизәк** тормыш яме (*рус.* Бизяк)
**Биксылу** бик сылу

# Г

**Гөл** чәчәк, матурлык, нәфислек символы
**Гөлбакты** гөл кебек кыз бакты, дөньяга карады, туды
**Гөлбизәк** гөл бизәк. Бизәкләү стиле

**Гөлбикә** гөл кебек матур бикә
**Гүзәл** мату, чибәр кыз
**Гүзәлбикә** гүзәл кыз
**Гүзәлия** гүзәллек иясе

# Е

**Елдам** җитез, өлгер
**Ефәк** ефәк кебек затлы (*рус.* Ипек)
**Ефәк**сылу ефәк сыман күркәм, сылу

# Җ

**Җиләк** җиләк-җимеш
**Җилкәй** *җил* сүзенә *–кәй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы өстәлгән. Җил сыман җитез, өлгер
**Җофар** 1. җофар[1]; 2. хуш ис

# И

**Иделбикә** Идел буе бикәсе (бай хатыны, аксөяге). *Русча синонимы:* волжская аристократка
**Илек** кыр кәҗәсе, косуля. Кыз балага җитез һәм нәфис булсын дигән теләк белән кушыла
**Илсөя** илен сөюче; илгә сөекле
**Илсөяр** (үзен) ил сөяр, ил, ватан сөеклесе
**Илүсә** бай, булдыклы, дәүләтле булып үсә мәгънәсендә
**Иркә** сөекле, кадерле
**Иркәбикә** сөекле, кадерле бикә (бай, бәк, би хатыны; аксөяк хатын-кыз)
**Иркәгөл** иркә гөл, чәчәк кебек кадерле, сөекле кыз

[1] Җофар – кыйммәтле мехлы җәнлек

**Ишбикә** гаиләне ишәйтүче кыз. Гаиләдә икенче яисә өченче кыз

**Ишембикә** анасына иш, тиңдәш бикә. Анасына охшаш кызга кушыла

# К

**Каплан** пантера. Кыз балага җитез, өлгер, уңган булсын, дигән теләк белән кушыла

**Каражә** киек, тау кәҗәсе. Өлгер, уңган булсын, дигән теләк белән кушыла

**Каракаш** кара кашлы сылу, чибәр кыз

**Каракүз** кара күзле матур, сылу кыз

**Карачәч** кара чәчле сылу, чибәр кыз (*рус.* Карачяч)

**Карлыгач** карлыгач кебек чибәр, җитез

**Кашбау – Кашмау** очлы итеп тегелгән баш киеме. Балага баш, җитәкче кеше булсын дигән теләк белән кушыла

**Кешбикә** *кеш* (соболь) һәм *бикә* сүзләреннән. Кадерле, кыйммәтле бикә

**Киленчек – Гәлинҗек** *килен-гәлин* сүзеннән (*рус.* невесточка). Гәлинҗек (Геленджик) – Кара диңгездә курорт шәһәре

**Кинҗә** төпчек кыз (*рус.* Кинзя)

**Котлыбикә** котлы (бәхетле) бикә

**Кояш** биеклек, игелеклек, яктылык мәгънәсендә

**Кояшбикә** *кояш* һәм *бикә* сүзләреннән

**Куаныч** сөенеч

**Кына** кына гөле

**Көмеш** затлы, кыйммәтле металл исеменнән. Рухи сафлык, пакълек символы

**Көнсылу** көн (кояш) сыман сылу

**Күркәм** күркәм, күрекле, затлы

**Күреклебикә** күрекле (сылу, чибәр) бикә (*рус.* изящная)

# Л

**Ләлә** яфраклары озын, кыңгыраусыман чәчәкле күпьеллык үсемлек, лилия

**Ләйсән** язгы беренче шифалы яңгыр

# М

**Мавиш** ак тәнле һәм зәңгәр күзле иш (бала, дус, иптәш)

**Миләүшә** фиалка чәчәге

**Миңлегөл** миңле, бәхетле гөл

**Миңлейөз** бәхетле, шат чырайлы

**Миңлесылу** бәхетле һәм сылу кыз

# Н

**Наз** үзен яраттырган, иркә. *Русча синонимнары:* нега, ласка

**Назлы** 1. иркә, грацияле; 2. иркәләүне, ягымлылыкны чагылдырган

**Нугайбикә** нугайларның бикәсе (аксөяк хатын-кызы)

**Нурдан** нурдан туган, илаһи зат

**Нурҗан** нурлы гүзәл, чибәр кыз

**Нурсал** нурлы, нур сибүче

# С

**Сакал** тәңкәләр төзеп ясалган изү, түшлек. Бизәнү әйбере буларак, матурлык символы. Сакал байларда гына булган

**Сандугач** былбыл. Нечкә хисләр, моң һәм мәхәббәт символы

**Сузгын** төз, озын, сузан

**Сузгынбикә** төз, озын буйлы бикә (*рус.* Сузгунбикя)

**Сулмас** сулмый торган чибәр кыз. Озын гомерле

**Сылу** гүзәл, зифа, матур сынлы

**Сылубикә** сылу бикә

**Сылукай** сылу кызга иркәләп-яратып әйтелә
**Сөембикә – Сөенбикә** сөемле (сөекле) бикә
**Сөенеч** куаныч, шатлык

# Т

**Такыя** кызлар баш киеме. Баш киеме белән бәйле исемнәр баш, өстен булсын дигән теләк белән кушыла
**Тамчы** саф, пакъ, җиңел сөякле
**Тансык** теләп, көтеп алынган кыз бала
**Татлы** татлы, кадерле бала
**Тату** тыныч яшәүче бикә
**Ташбикә** таш сыман нык, таза бикә. Бала авырмасын, дип бирелгән исем
**Таңбикә** таңда туган бикә, таң кызы
**Таңгөл** таң гөле
**Таңйолдыз** таң йолдызы (Чулпан), *рус.* Танюлдуз
**Таңсу** таң сыман, таңга охшаш
**Таңсылу** таң кебек сылу
**Тиңбикә** тиң бикә
**Торгы** ефәк, ефәк кебек затлы (*рус.* Тургу)
**Туйбикә** туй (бәйрәм) көнне туган бикә
**Тукбикә** тук, җитешкән бикә (*рус.* совершенная)
**Туксылу** тук сылу, ягъни һәръяктан камил, җитлеккән сылу. Кимчелексез
**Тулганай** тулган айда туган кыз
**Тәңкә** көмеш тәңкә – сафлык, пакълек билгесе (*рус.* Деньга)
**Төзбикә** төз, сылу гәүдәле бикә (*рус.* Тюзбике, Тюзбикя)

# У

**Ука** ука, вак энҗе. Матур, чибәр бикә
**Укабикә** ука кебек чибәр бикә

**Уразбикә** ураз (бәхетле) бикә (*рус.* Уразбике, Уразбикя)
**Уразгөл** ураз (бәхет) гөле (*рус.* Уразгуль)

# Х

**Ханбикә** хан бикәсе, хатыны
**Ханбикәч** хан бикәче, хатыны

# Ч

**Чия** чия кебек татлы
**Чиябикә** чия кебек татлы бикә
**Чулпан** таң йолдызы
**Чәчбикә** чәчле бикә. Озын чәчле булып туган балага бирелгән йола исеме (*рус.* Чечбике)
**Чәчкә** чәчәк
**Чәчкәбикә** чәчкә кебек бикә
**Чәчкәгөл** чәчкә, гөл
**Чәчәк** чәчәк – гүзәллек, матурлык, сафлык символы (*рус.* Чечек)

# Я

**Язгөл** яз гөле
**Язгөлем** яз гөлем
**Якут** якут ташы, яхонт
**Ялкын** ялкын кебек
**Яңабикә** гаиләдә икенче кыз бала. *Рус.* Янабике
**Яркәй** кояшны белдергән *ярк* **(***ярек, ярык)* сүзенә *–әй* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы өстәлгән. Мәгънәсе: кояш кебек нур, яктылык чәчүче[1]
**Яулыбикә** яу, сугыш вакытында туган бикә (кыз)
**Яхшыбикә** яхшы, чибәр кыз. *Рус.* Яхшибике
**Яхшыгөл** гөлдәй чибәр кыз

---

[1] Рус теленә бик борынгы бу төрки сүз “яркий” буларак кергән

*Габдулла ТУКАЙ*

## *Исемнәремез хакында*

(...) Бала зәгыйфь; мәүҗүдат галәмендә[1] бер әсир. Аңар, әлбәттә, берәүгә-берәүгә тәслим ителүдән[2] бүтән чара юк. Ул бичара ата-анасына тәслим ителә.

(...) Хуш. Бала шулай тәслим ителә. Аның атасы яһүди булса, бала киләчәктә яһүд милләтенә хезмәт итәрлек рәвештә тәрбия ителә.

Атасы нәсрани[3] булса, янә, нәсрани милләтенчә тәрбия кыйлынып, киләчәктә үз милләтенә файдалы бала булуы күзгә алына.

Мәҗүсиләр тугърысында (1904 сәнәдә эш күрсәткән) япон балаларын күрсәтсәм, җитсә кирәк. Әйе, алар мәҗүс милләтенчә тәрбия кыйлынганнар.

Менә без, татар балалары да, татар милләтенчә тәрбия кыйлынганбыз.

Юк, бу сүз хата, бик зур хата! Без татар милләтенчә тәрбия кыйлынмаганмыз, бәлки татар диненчә тәрбия алганбыз.

Без моны анадан тугач та үземезгә кушылган исемнәрдән истидлял итә[4] алабыз. Менә исемнәр: Гайнетдин, Сәйфетдин, Котбетдин, Нуретдин, Баһаветдин, Гыйльметдин, гайре мөтәнаһи[5]...

---

[1] *Мәүҗүдат галәме* — реаль дөнья
[2] *Тәслим ителү* — бирелү, тапшырылу
[3] *Нәсрани* — христиан динендәге кеше
[4] *Истидлял итү* – нәтиҗә ясау
[5] *Гайре мөтәнаһи* — чиксез

Бала тугъды. Атасы ат кушарга мулла чакырды. Атасы чәпчим риза булып җитмәгән булса да, анасы чаршау аркылы гына: «Хәзрәт! Баланың исемен Гайнетдин куш!» — диде.

Бәс, Гайнетдин дигән сүзнең мәгънәсе ничек? «Гайн» ләфзының[1] 8 төрле мәгънәсе булса да, бу урында Гайнетдин, ягъни диннең нәкъ үзе, гайне үзе дигән мәгънә морад.

Инде, әфәнделәр, мин сезгә бер сөаль бирәм: сезгә урамда җөргән вакытыбызда бишбилле бишмәтле, тездән генә чалбарлы, кырган мыек, озын сакаллы, чалбар бавы салынган, яшел читекле бер татар очраганы бармы?

Очраган булса, моның исеме — Гайнетдин, бу үзе дә Гайнетдин, ягъни килеш-килбәте, кием-салымы белән диннең гайне үзедер. Димәк, исеме җисеменә муафикъ[2].

Аннан соң, мөхтәрәм укучылар, иренсәгез дә җавап бирә күреңез:

Сез, «Бу эш шәригатькә сыймый; дәһриләр динне бетерәләр: менә мин аларны!» — дип йозрыгын төенләп, ава-түнә җөргән исерек татарны күргәнеңез бармы?

Күргәнеңез булса, менә бу кеше Сәйфетдин инде, ягъни бу — диннең кылычы. Кем белә, бәлки, зөлфекарыдыр[3] да!

Мөхтәрәм укучылар!

Сез яңаклары ябышкан, күзләре чекрәйгән, өстенә җилән, башына керле чалма кигән бер пишкадәмнең[4] үзенә җиһанда тиң тапмаган сыман аска карап җөргәнен күргәнеңез бармы?

Күргән булсаңыз, бу абый Камалетдин булыр, ягъни диннең кәмале вә ниһаяте[5] булыр. Артык юк.

---

[1] *«Гайн» ләфзы* — «гайн» дигән сүз

[2] *Исемнең җисеменә муафәкате* — исеме кешенең үзенә туры килүе

[3] *Зөлфекар* — бик озын һәм гаять үткен кылыч (фольклорда)

[4] *Пишкадәм* — мәдрәсә программасын тәмамлагач, муллалыкка урын көтеп ятучы шәкерт

[5] *Кәмале вә ниһаяте* — иң югары дәрәҗәсе һәм чиге

Эзләмә. Иҗтиһад габәс[1] вә мөнкариз[2].

Шулай, исеме җисеменә муафикъ.

Исемнең җисемгә муафәкате бик матлуб[3] вә мөгътәбәр бер эштер.

Мәсәлән, бер шәкерт болай дип җырлый:

Исме җисменә муафикъ
һәм Камилә, Мөршидә;
Булмыйдыр түзеп күралмый,
Көн дә барып күршегә.

Истанбулда ниндидер бер пашаның угылы туа. Шуның шатлыгына паша йортында зур зыяфәт[4] була. Зыяфәттә бер шагыйрь дә иштиракъ итә[5]. Пашаның угылына Гали исеме кушылачак булгач, шагыйрь әфәнде угъланга төбәп шушы түбәндәге шигырьне сөйли:

Эстәрем: исмиң кеби, затыңда да
Мәгънаэ голувият улсын мөнҗәли;
Шимдидән нәкыш ит шу кәнди кальбеңә:
Садә исмиң улмасын, угълым, Гали[6].

Ягъни, и паша угылы! Синең исемең дә җисемеңә муафикъ булсын!

Бу китергәнем дәлилләр белән мин исемнең җисемгә муафикълыгы мәмдух вә матлуб[7] икәнлеген исбат иттем бугай.

---

[1] *Габәс* — файдасыз

[2] *Мөнкариз* — беткән, сүнгән

[3] *Матлуб* — теләк итеп тотыла торган

[4] *Зыяфәт* — аш-су мәҗлесе

[5] *Иштиракь иту* — катнашу

[6] Телим: исемендәге кебек, үзендә дә бөеклек мәгънәсе балкып торсын; шушы юлны хәзер үк күңелеңә сызып куй, улым: Гали дигән исем сиңа гади исем булып кына калмасын.

[7] *Мәмдух вә матлуб* — мактаулы һәм кирәкле

Аңлашылды ки, без татарларның тәрбиясе — дин тәрбиясе, һәр абзый, һәр агай, һәр бабай диннең ни булса да бер кирәк нәрсәсе: Гыймадетдин, Мифтахетдин, Микъразетдин (терәге, ачкычы, кайчысы).

Дингә изафә кыйлынган[1] исемнәремез хакында җитәрлек сабсата саттым инде.

Соң, Аллага мозаф[2] исемнәр хакында ни дибез? Болар да исәпсез күп ич: Габдулла, Миңнулла, Лотфулла, Гайнулла, Шәмсулла, Гобәйдулла, Гыйбадулла, Сәйфулла, Әхмәдулла, Хәкимулла, Галимулла вә гайре вә гайреләр.

Бу Аллага изафәнең мәгънәсе, минемчә, болайдыр:

Безгә тугач та үземезгә мөстәкыйль бер адәм булырга исем җәһәтеннән үк юл калдырылмый.

Без — Габдулла, ягъни ниндидер бер Алла бәндәсе.

Без — Гобәйдулла, ягъни ниндидер Ходай колчыгы.

Без — Гыйбадулла, ягъни ниндидер Алла коллары.

Без — Әхмәдулла, ягъни Алланың бер әхмәте[3]!

Без — Рәхмәтулла, ягъни Алланың бер мәрхүме.

Менә бу ямьсез, мәгънәсез, тозсыз, мөрәккәб[4] исемнәр — һәммәсе дә безнең диндар Бохара җимешләре булган хәзрәтләремез хезмәте!

Монда, әлбәттә, исемнәр җисемнәргә муафикъ. һәммәбез Алла бәндәсе һәм оҗмахка керәчәк Гозәер галәйһиссәлам ишәге, ягъни Ходай ишәге.

Тикшерә башлагач, туктамыйк инде: соң бу Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Нигъмәтҗан, Сәлимҗан, Галимҗан, Гарифҗан, Са-

---

[1] *Дингә изафә кыйлынган* — «дин» дигән сүзгә ияртелгән

[2] *Аллага мозаф* — «Алла» дигән сүзгә ияртелгән

[3] *Әхмәт* — беренче

[4] *Мөрәккәб* — кушма

лихҗан, Шакирҗан исемнәре ничек? Салих, Шакир, Мөхәммәт, Әхмәт кеби саф гарәп сүзләре катына бу «җан» сүзләре кайдан килеп катышкан?

Җан — «рух»мы? Җан — Коръәндә мәзкүр җен нәүгыннән[1] булган җанмы? Җан — «җанмак»тан әмерме[2]? Әллә «минем җанымда» (катымда) дигән сүздән алынганмы?

Түгел, түгел, бу әйтелгәннәрнең берсе дә түгел!

Безнең муллалар Бохара җимешләре яки бәрәңгеләре икәне бәян ителгән иде. Мәгълүмдер ки, Бохараи кабих мәхфузә билләүате шәһәрендә сартлар яшь угъланларга «җанкәем», «җанашым» дип үк әйтмәсәләр дә, авызларына шәһвәт күбекләре чыкканы хәлдә: «Фәлән җан! төгән җан!» — дип хитап әйтәләр, мәсәлән, Хәким исемле бер гүзәл бала күрсә, сарт: «Хәким!» — дип хитап әйтә алмый, бәлки, күзләрен майландырып: «А Хәким җан!» — дип җибәрә.

Менә шул фәкать, фәкать хәйваният вә шәһвания т[3] хисеннән туган «җан» ләфзын[4] безнең муллалар түкми-чәчмичә Русиягә алып кайтканнар. Алып кайту белән генә канәгатьләнмичә, безнең Чыңгыз, Тимер, Туктамыш, Алтынбик, Япанчы кеби гүзәл милли исемнәремез урынына шул Сәлим«җан», Галим«җан» кеби мөрәккәб, ямьсез, татарлар өчен хурлык, әйтергә тел теләми торган исемнәрне тудырганнар.

Кем белә, бәлки, остазлары сартлар кеби, шуннан хушланганлардыр да.

Мин бу сүзләрне без татар балаларына анадан тугач ук әл-

---

[1] *Нәүгыннән* — төркеменнән

[2] *«Җанмак»тан әмерме?* — «Янмак» дигән сүздән боерык формасымы?

[3] *Шәһвания т* — җенси

[4] *Ләфзын* — сүзен

лә нинди истикъбалемез[1] өчен яман фаллы вә мәшьум[2] исемнәр тагылганына эчем пошканнан яздым.

Һәр нәрсәнең гүзәлен яратабыз бит. Бәс, мин телимен ки, Бохари муллаларның бөтен черек нәрсәләренә безнең арада бәһа беткән кеби, киләчәктә ул әфиюн башлар уйлап чыгарган ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын. (...)

[1] *Истикъбаль* — якты киләчәк

[2] *Яман фаллы вә мәшьум* — начарлык юраучы һәм шомлы

## *Файдаланылган әдәбият исемлеге*

Әхмәтҗанов М.И. Татар кулъязма китабы. – Казан, 2000.

Әхмәтҗанов М.И. Турай, Миякә арасы – бар да меңнәр баласы. – Казан, 2010.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүлеге. – Казан, 2001.

Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. – Казан, 2003.

Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан, 1997.

Баскаков Н.А. Русские фамилии тюркского происхождения. – М., 1979.

Гомәр Саттар-Мулилле. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан, 1998.

Магницкий В.К. Чувашские языческие имена. – Казань, 1905.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан, 2005.

Татарча-русча сүзлек. – Мәскәү, 1966.

Федоров М.Р. Словарь чувашских нехристианских личных имен. – Чебоксары, 1998.

Шайхулов А.Г. Татарские и башкирские личные имена тюркского происхождения. – Уфа, 1983.

Ali Püsküllüoğlu. Seçilmiş çocuk adları sòzlüğü. – İstanbul, 2005.

Kâşgarlı Mahmûd. Divânü Lugâti’t-Türk. – İstanbul, 2005.

# ЭЧТӘЛЕК

*Беренче бүлек.* ИСЕМ КУШУ

Бәхет китерүче исемнәр ........................................................ 3

Исем кушу тәртибе ................................................................ 5

Нигә татарларның фамилияләре юк? .................................. 7

"Татар исеме булмый, кем исеме булсын тагын?.." ......... 12

*Икенче бүлек.* ТАТАР ИСЕМНӘРЕ

Бәхет китерүче ир-ат исемнәреннән үрнәкләр ................. 16

Бәхет китерүче хатын-кыз исемнәреннән үрнәкләр ........ 47

*Кушымта.*

Габдулла Тукай. Исемнәремез хакында ............................ 55

**Файдаланылган әдәбият исемлеге** ................................ 61

# АННОТАЦИЯ

Личные имена татар, особенно антропонимы домусульманского периода изучены недостаточно. Актуальной является также проблема исследования их фамилий – наследственных семейных именований как особого лингвокультурного феномена.

Данная книга посвящена анализу татарских антропонимов тюркского происхождения, бывших в употреблении до принятия ислама, а также отчасти употребляющихся и сегодня. В первой главе «Имянаречение» рассматриваются вопросы происхождения и развития татарской антропонимии, словообразовательные особенности личных имен и фамилий. Во второй главе «Татарские имена» проанализированы личные имена тюркского происхождения, их семантика и этимология.

У людей, принадлежащих к разным культурам, территориям, ономастическое пространство имеет различное заполнение, так как имя рождается как словесное отражение традиций, обычаев, нравов народов. Татарская антропонимическая система – явление сложное и ее главное своеобразие заключается в превалировании внеязыковых – идеологических и религиозных факторов развития над языковыми. Автор отмечает, что в татарских именах слабо отражены национальные идеалы народа, его чаяния, своеобразие понимания окружающего мира. Не только в татарскую, но и в тюркскую антропонимию в целом проник огромный пласт арабо-мусульманских терминов, которые стали доминировать и даже подавлять собственную онимическую лексику.

Интересны размышления автора о характере татарских фамилий. Указывается, что у татар отсутствуют фамилии (родовые имена) как таковые. Фамилия, точнее онома-источник фамилии (прозвище), как правило, происходит от нарицательного слова. Эти онома-источники и градуируются исследователями по своему происхождению (например, от названий животных, растений, явлений природы и т.п.). По мнению автора, в случае с татарами еще не видно фамилий, налицо лишь имена отцов и дедов.

**Ключевые слова**: татарские имена, тюркские антропонимы, лексика тюркского происхождения, русские фамилии, татары и ислам

*Научно-популярное издание*

Девбаш Фирдус
(Фатклисламов Фирдус Нурисламович)

**ИМЕНА, ПРИНОСЯЩИЕ СЧАСТЬЕ.**

**Толковый словарь тюрко-татарских личных имен**

*(на татарском языке)*

Сдано в набор 20.06.2016. Формат 60x84 $^{1}/_{16}$. Офсетная бумага.
Гарнитура «Times New Roman».
Усл. п.л. 4. Тираж 50 экз.

Издательство «Ихлас». 420043, г.Казань, ул.Вишневского, 26а.
Тел.: 89172836545
E-mail: ilfaz@mail.ru

Фәлсәфә галиме һәм язучы **Фирдүс Дәүбаш** татар укучысына халкыбызның үткәне, бүгенге көне һәм киләчәге турындагы тирән уйланулары белән таныш. Ул үз әсәрләрендә дөньяның ямен күрсәтә, бәхеткә ирешү юлларын ача, тормышта барысы да диярлек кешенең үзенә бәйле булуын аңлата. Аның иҗаты укучыга яшәү көче өсти һәм шуның белән җәлеп итә.

Фирдүс Дәүбаш онытылып килгән рухи мирасыбызны кайтарырга тырыша. Кулыгыздагы бу китап та шул нияттән чыгып әзерләнгән. Биредә саф татар исемнәре тупланган, аларның мәгънәләре, нинди очракта балага кушылырга тиешлеге аңлатылган. Татар исемнәре халкыбызның милли йөзен, сыйфатын, шанлы тарихын саклый, – ди Фирдүс Дәүбаш.

Авторның Интернеттагы үз сайты: **www.devbas.ru**

адресы: **devbas@yandex.ru**